Тиш батыр

Биш батыр



ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕ

Рушан Шәмсетдинов рәсемнәре

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2001

ББК 82.3(2Рос=Тат)
Б25

УРТА ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

Б25 **Биш батыр:** Татар халык әкиятләре.— Казан: Татар.кит.нәшр., 2001.— 84 бит.

Әлеге китапка халкыбыз яратып укый һәм тыңлый торган әкиятләр туплап бирелде. Курку белмәс һәм җиңелмәс баһадирлар турындагы «Камыр батыр», «Турай батыр», «Таңбатыр», «Дутан батыр» әкиятләре Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институты хезмәткәрләре тарафыннан татар авылларында язып алынган. Румыниядә яшәүче Добруҗа татарларыннан күчереп алынган «Чура батыр» дастаны исә сезнең игътибарга язучы Флүс Латыйфиның әдәби эшкәртүендә тәкъдим ителә.

ISBN 5-298-01057-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2001

КАМЫР БАТЫР

Борын-борын заманда, кәҗә команда, әби-бабай тумас борын, әти белән икәү генә торган чагында, бар иде, ди, бер карт белән карчык. Аларның балалары юк иде, шуңар кайгылары бик зур иде, ди.

Берзаман болар исәпләделәр, уйладылар да камырдан бер бала сыны ясап куйдылар, ди. Әби чыгып китте сыер саварга, бабай чыгып китте, ди, утын ярырга.

Керсәләр, исләре китте, акыллары таралды: камыр сыны, малай булып, кәҗә бәтиләре белән чабышып уйнап йөри, ди.

Камыр малай төн үсә, көн үсә, ай үсәсен көн үсә, ел үсәсен ай үсә, ди. Бабай ясап бирде, ди, моңа шартаяк. Малай бер таянган иде, ди, шартаяк шарт итеп сынды, ди. Төшеп китте, ди, бабай тимерчегә, ясатты, ди, моңа тимер шартаяк. Малай беркөнне урамга чыга — бер малайның аягын сындырып керә. Икенче көнне чыга — икенче малайның муенын сындырып керә, ди.

Шуннан соң авыл халкы җыелып бабайга әйтәләр:

— Малаең малай төсле түгел, балаларны имгәтеп бетерә, теләсәң кая куй! — диләр.

Чыгып китә, ди, малай дөнья гизәргә. Ай китә, ел китә, бер саплам җир китә. Барып керә, ди, бу бер карурманга. Очрый моңа аягын тышаулаган бер кеше.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп тышауладың бу аягыңны? — ди.

Теге кеше әйтә:

— Миңа болай да таманга килә әле, аягымны ычкындырсам, мин күккә очам, минем арттан кош-корт та очып җитә алмый,— ди.

Камыр батыр моны үзе белән ияртеп китә.

Баралар-баралар, бара торгач, очрый боларга борын тишеген бармагы белән кысып утырган бер кеше.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп болай борын тишегеңне кысып утырасың? — ди. Теге кеше әйтә:

— Миңа болай да таманга килә әле, ди. Югыйсә дөньяда зилзилә куба, бер борын тишегем белән өрдереп тә биш ташлы тегермән әйләндерәм мин,— ди.

Камыр батыр моны да үзе белән ияртеп китә.

Баралар-баралар, ди, болар. Очрый, ди, боларга эшләпәсен кырын салган ак сакаллы бер бабай.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп болай эшләпәңне кырын гына салдың? — ди.

Теге бабай әйтә:

— Миңа болай да таманга килә әле,— ди.— Мин эшләпәмне туры кисәм, күз ачмаслык буран чыга, басып кисәм, җир йөзенә ике илле боз ката,— ди.

Камыр батыр монысын да үзе белән ияртеп китә.

Баралар-баралар болар. Очрый, ди, боларга ук төзәп торучы тагын бер кеше.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нәрсә атасың син болай? — ди.

Ук төзәп торучы әйтә:

— Ә-ә-нә, күрәсеңме, теге тауның кабыргасында, моннан алтмыш чакрым җирдә, бер чебен утыра. Шул чебеннең сул күзен атып чыгарам,— ди.

Камыр батыр моны да үзе белән ияртеп китә.

Тагын китәләр. Беравык баргач, очрый боларга туфрак белән уйнап утырган сакаллы бер кеше.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп болай уйныйсың? — ди.

Сакаллы кеше әйтә:

— Бу яктан сугам — бу якка тау өям, теге яктан сугам — теге якка тау өям,— ди.

Камыр батыр монысын да үзе белән ияртеп китә.

Барып җитәләр болар бер байга, сорыйлар моның кызын. Бай бик кире була, төрле хәйләләр кора.

— Минем кызым — бай кызы,— ди,— патша кызыннан ким түгел, синдәйләргә тиң түгел,— ди.— Әйдә, миннән булсын яхшылык,— ди,— йөгерешчемне узсаң, бирсәм бирермен инде,— ди.

Китәләр йөгерешкә. Аягын тышаулаган егет алтмыш чакрым җирне бер-ике сикерүдә барып җитә дә, бай йөгерешчесе килеп җиткәнче дип, тау өстендә йоклап китә. Байның йөгерешчесе йөгереп мәйданга якынлашып килгәндә теге һаман йоклаган була.

Камыр батыр әйтә:

— Ай-һай,— ди,— бай малае җиңә бит,— ди.— Ат әле тегеңәр,— ди.

Алтмыш чакрымнан чебеннең сыңар күзен атып алучы кеше атып җибәрә, йөгерешченең колак яфрагын чеметтереп ала. Йөгерешче уянып китә дә мәйданга бай йөгерешчесеннән алда килеп җитә.

Хәзер бай алай итә, болай итә, боларны алдап чуен мунчага яба. Әрдәнә-әрдәнә утын өйдерә, ут төртә, боларны яндырып үтермәкче була. Болар мунча эчендә пешә башлыйлар. Камыр батыр бабайның эшләпәсен туры кидерә — мунча эчендә күз ачмаслык буран кузгала. Алай да пешә башлыйлар, ди. Камыр батыр бабайның эшләпәсен бастырып кидертә — мунча стенасына ике илле боз ката.

Икенче көнне бай мунча ишеген ачып җибәрсә, ботын чабып шакката: барысы да исән.

Камыр батыр әйтә бу байга:

— Башымны катырма инде,— ди.— Алыштанмы, салыштанмы? — ди.

— Алыштан да булыр,— ди,— салыштан да булыр,— ди.— Минем сиңа бирә торган кызым юк, көчең җитсә, алырсың,— ди бай.

Китте алыш, китте егып салыш. Шундый алыштылар, шундый салыштылар, ди: тигез җирләр түмгәк булды, түмгәк җирләр тигезләнде, ди. Көн сугыштылар, төн су-

гыштылар, кич сугыштылар, бик озак сугыштылар, ди. Бер борын тишеге белән өрдереп биш ташлы тегермән тарттыручы кеше борын тишеген сызгырттырып җибәрә — байның егерме кешесе очып китә. Туфрак белән уйнаучы бер яктан сугып җибәрә — утыз кеше күмелә, икенче яктан сугып җибәрә — кырык кеше күмелә, ди. Камыр батыр күсәге белән бер селтәнә, әллә нихәтле кеше кырылып бетә.

Бай түзә алмаган, кызын бирергә булган, ди. Кызны Камыр батырга биргәннән соң, утыз көн уен итеп, кырык көн туен итеп, тумаган ала биянең итен пешереп, бик каты сыйлаганнар, ди. Туйларында мин дә булдым, аш-суның чиге юк, бәлешләрнең төбе юк, мичкә-мичкә бал куйганнар, үзләре чүмеч белән чумыралар, миңа сабы белән эләкте.

ТУРАЙ БАТЫР

Булган, ди, борын заманда бер хатын. Аның булган, ди, өч өе: берсе кешенеке, берсе күршенеке, берсе салмаган, бурасын да алмаган, шунлыктан ул алачыкта гына торган, ди. Алачыгы шәп икән: һава белән каплаган, җилләр белән мүкләгән. Ач иде, ди, ул, тук иде, ди, алачыкта гына торса да, кешегә чыгу гадәте юк иде, ди.

Шул хатынның булган, ди, Турай атлы бер улы. Чамасыз да гәүдәле, чамасыз да көчле булган, ди, ул егет. Күрешим дисә, кешенең кулын имгәткән, атланыйм дисә, атның билен сындысан, көрәшләрдә моңа батыр чыкмаган, якын-тирәдә берәү дә калмаган мәйданда бу екмаган. Турай батыр да Турай батыр дип моның исеме телләрдән төшми икән, ди. Тик бу егетнең бер кайгысы бар икән. Буйга-сынга килсә дә, төскә-биткә чибәр булса да, аңа кызлар чыкмаган. Турай яучы җибәрсә, кулларын гына селкиләр иде, ди. Алачыкта торган кеше кая килен төшерсен дә, кайда бала үстерсен?

Шулай йөргән-йөргән дә бу, анасына шундый сүз әйткән:

— Әни, китимче мин,— дигән.— Читкә чыгыйм, ил-көн күрим, дөнья гизеп йөрим. Бәлки, кулга мал төшәр, бәлки, берәр кыз очрар, сиңа килен, миңа хатын чыгар.

Анасы әйткән:

— Ай, улым, китүен китәрсең анысы, син бит минем бер генәм. Китеп югалсаң, синсез нишләрмен, сиңа ул-бу булса, хәлеңне ничек белермен?

Егет каз каурыен алган да матчага кыстырган:

— Син кайгырма, әни,— дигән,— мин югалмам. Әгәр инде миңа ул-бу була калса, шушы каурыйдан кан тамар.

Анасының рөхсәтен алып, билен буып, кулына кистәнен алып, чыгып китте, ди, бу егет. Бара, ди, бу, бара, ди. Көн китте, төн китте, артына борылып караса, карыш буе җир китте. Шулай да, бара торгач, биек тау буена барып җитте, ди. Гөрелдәгән тавышка күтәрелеп караса, ике тау бер-берсе белән чәкәшә. Якынрак килсә, шаккатты: бу тауларны бер батыр шулай бер-берсенә бәреп чәкәштереп утыра икән.

Турай батыр моннан сораган:

— Бу тауларны нигә болай чәкәштерәсең? — дигән.

Теге егет әйткән:

— Синең киләсеңне белдем дә чакма чагып, ут чыгарып, ботка пешермәкче булдым,— дигән.

Бу батыр Тауказар атлы булган, ди.

Ярый, болар хәзер ике иптәш булдылар, ди. Тагын киттеләр, ди, бара торгач, очраган, ди, боларга өченче батыр. Монысы ташны сыга да ыргыта, сыга да ыргыта, ди.

— Бу ташларны нигә болай сыгасың? — дип сорадылар.

Теге батыр әйтте, ди:

— Сезнең киләсегезне белдем дә, ботка пешерим дип, таштан май чыгарып маташам.

Бу батыр Ташказар атлы булган, ди.

Ярый, болар хәзер өч иптәш булдылар, ди. Тауказар белән Ташказар шулай ил-көн күрергә, бәхет эзләргә чыкканнар икән.

Киттеләр, ди, шулай өчәү иптәш булып, көн китеп, төн китеп, кырлар үтеп, күлләр-дәрьялар кичеп, барып җиттеләр, ди, болар бер карурманга. Шундый калын, шундый караңгы, ди, гомергә дә бер кеше аяк басмаган.

Бара торгач, күрәләр болар бер йорт. Эченә керсәләр, идән уртасында учак, учак янында казан, өй түрендә сәке, сәке өстендә табак, табак эчендә кашык. Бөтен дирбиясе бар, тик хуҗалары гына юк.

Бер төн куналар бу йортта, ике төн куналар, һичкем күренми. Шуннан соң уйлашалар:

— Монда туктап бераз ял итик, кош-корт аткалыйк, аннан соң күз күрер.

Тауказар белән Турай чыгып китәләр ауга, Ташказар өйдә аш пешереп кала.

Аш өлгерде дигәндә генә берәү ишекне кага:

— Ач ишекне!

Ташказар ишекне ачуга, батыраеп-ирәеп килеп керә бер кәрлә: үзе бер карыш, сакалы биш карыш.

— Сәкегә күтәреп утырт! — ди.

Ташказар утырта.

— Аш бир! — ди.

Ташказар табакка салып аш та бирә.

— Миңа болай гына җитми, казаны белән китер! — ди.

Ташказар:

— Юк, казаны белән бирә алмыйм, иптәшләремне туйдырасым бар,— дип әйтә генә башлаган иде дә, үзе бер карыш, сакалы биш карыш аңа аяк тибеп кенә кычкыра:

— Әһә, әле син шулаймы? Китер тизрәк!

Шуннан соң Ташказар ашны казаны белән китереп куя. Үзе бер карыш, сакалы биш карыш ашны ашап бетергәннән соң сикереп төшә дә, тагын да батыраеп, Ташказарны үтереп, китеп тә бара.

Турай батыр белән Тауказар кайтып керсәләр, ни күзләре белән күрсеннәр, иптәшләре үлгән, ашны кемдер ашаган. Табак-савыт идәндә аунап ята.

— Бу нихәл бу? — диләр.— Монда килеп безнең иптәшебезне үтерергә кемнең батырчылыгы җиткән?

Кайгырышалар, үкенешәләр инде болар. Ташказарны, мәрткә киткән булмагае дип, сарайга чыгарып куялар да, икенче көнне Турай батыр ауга үзе генә чыгып китә.

Тауказар ашны өлгертеп кенә җиткергән иде, тагын ишек кагалар:

— Ач ишекне!

Тауказар ачып кертә. Батыраеп-ирәеп килеп керә бер кәрлә: үзе бер карыш, сакалы биш карыш.

— Күтәреп утырт! — ди.

Тауказар күтәреп утырта. Тагын ашны казаны белән сорый да, Тауказар бирмәгәч, аны үтереп, ашны ашап, өй эчен туздырып тагын чыгып югала.

Турай батыр кайтса, Тауказар да үлгән. Бик аптырады инде бу, кайгырды. Кем эше булыр икән бу? Күз күрмәгән, колак ишетмәгән бу нинди хәл?

Ул көнне Турай батыр ауга чыгып тормады. Аш пешеп кенә өлгергән иде, тагын ишекне дөбердәттеләр:

— Ач ишекне!

Турай батыр әйтте:

— Килә белгәнсең икән, ача да бел!

Үзе бер карыш, сакалы биш карыш бу юлы ишекне үзе ачып керә.

— Сәкегә күтәреп утырт! — ди.

— Керә белгәнсең икән, менеп утыра да белерсең.

Үзе бер карыш, сакалы биш карыш бу юлы сәкегә дә үзе менеп утыра. Үзе сәке өстендә, сакалының очы ишек төбендә.

— Аш бир!

Турай батыр әйтте:

— Ашыйсың килә икән, үзең пешереп аша.

Шулай гына дигән иде, үзе бер карыш, сакалы биш карышның сикереп төшүе була, болар дөнья куптарып сугыша башлыйлар. Турай батыр тегене сакалыннан урап алып китереп бәрә, үзе бер карыш, сакалы биш карыш тез тиңентен идәнгә иңә. Үзе бер карыш, сакалы биш карыш моны шундый тотып чөя. Турай батыр өйнең өрлекләрен, кыекларын җимереп күккә очып китә. Көн сугыштылар болар, төн сугыштылар, шулай да өченче тәүлеккә киткәндә, үзе бер карыш, сакалы биш карыш Турай батырны җиңде.

Үлде бит инде Турай батыр. Аның үлүе була, матчага кыстырган каурыйдан кан тама башлый. Турайның анасы моны күреп ала да зар елап юлга чыгып китә.

— Ай, балам! — ди.— Ниләр булды сиңа, кайда син?!

Турайның анасы бөтенләй үк буш хатын түгел икән. Кайда җәяү, кайда ат белән, кайда тауларны турыдан кичеп, кайда әйләнеп юлларны турайтып бара торгач, килеп тапты, ди, бу улын. Укыды, ди, ялварды, ди, өрде, ди, улының күкрәгенә җылы сулышын. Шулай итә торгач, Турай күзен ачты, ди.

— Уф, ай-яй, озак йоклаганмын икән! — дип әйтте, ди. Моңарга каршы анасы әйтте, ди:

— Ай, балам, ярый әле мин килеп җиттем, югыйсә мәңгегә йомылган идең бит.

Шуннан соң Турай батыр анасыннан иптәшләрен дә терелтүен үтенергә тотынган. Әмма анасы әйткән:

— Ай-һай, балам, булырмы икән? Мин бит сине балам булганга, үземнең йөрәк җылымны өреп кенә терелттем,— дигән.

Турай батыр анасыннан яңадан ялына башлаган:

— Алар миңа туганнарым кебек якын, терелтсәнә, әни,— дигән.

Шуннан соң анасы озак уйланып торган да әйткән:

— Ярый, ана булган кеше баласы хакына кулыннан килгәнне кызганмас, тик син белеп тор, боларны терелтсәм, сулыйсы сулышларым кыскарыр, юньле кеше булсалар гына терелтәм,— дигән.

Тагын шулай, улын җылыткан шикелле, күкрәкләренә җылы сулышын өреп, Турайның иптәшләрен дә терелткән. Тик үзе шунда ук хәлсезләнеп ауган.

Өч егет Турайның анасын бик тәрбияләгәннәр. Урман тавыгының ите, пошиларның сөте белән туйдыра торгач, карчыкка бераз хәл кергән. Аны бик хөрмәтләп, исәнсау авылына озатканнар да өч батыр тагын юлга чыгып киткәннәр.

Үзе бер карыш, сакалы биш карыш Турай батыр белән алышканда бик каты яраланган икән, аның ярасыннан юл буенча кан агып барган, ди. Бара торгач, җиткәннәр болар бер коега. Шунда эз беткән. Турай батыр әйткән:

— Коега мин төшәм, вакыт җиткәч, сезгә белдерермен, тартып чыгарырсыз, дигән.

Турай батыр төшеп баскан икән, кое төбе коп-коры. Күзе ияләнә төшкәч, караса, бөтенләй башка дөньяга килеп төшкән бу. Ерак та түгел, шәһәр сыман нәрсә дә күренеп тора икән. Тик шул яктан бик яман бер акырган тавыш ишетелә, ди.

Шәһәр читендә яшәүче бер әбигә керә дә сорый бу:

— Әби, бу нинди яман аваз? — ди.

— Ә,— ди карчык,— диюләр патшасы, патша кызлары урлап кайтырга дип дөньяга чыккач, батырлар белән сугышкан да шунда бик каты яраланып кайткан, диләр. Сызлануына түзә алмыйча кычкыра торгандыр.

Турай батыр тагын карчыктан сорый:

— Әби, дию патшасын ничек күрергә икән? Моңарчы минем тере патша бер дә күргәнем юк әле,— ди.

— Ай-һай, улым,— ди карчык.— Әллә барып йөрмисеңме? Аңа патша кызларын коткарырга дип нинди генә батырлар барып карамады. Тик моңарчы берсенең дә исән чыкканы юк әле.

Анда патша кызлары да булгач, Турай батыр бигрәк тә кызыксына башлый инде. Аның бит әле үзенә иш булырдай бер кыз да табасы бар.

— Ни булса булыр, әби, барыйм инде мин, юлын гына өйрәтсәнә! — ди.

Шулай бик йодәтә торгач, карчык өйрәтсә дә өйрәтә, өйрәтмәсә дә өйрәтә:

— Менә шулай-шулай барасың,— ди.— Диюнең үзен, көчең җитсә, көч белән җиңәрсең,— ди.— Тик сакчыларын көч белән дә түгел, усаллык белән дә түгел, яхшылык белән генә җиңә алырсың. Бер йөк печән, бер түш ит, кием-салым, ашамлык-эчемлек алып бар.

Турай батыр бу киңәшне шыпырт кына тыңлап барысын да әби әйткәнчә эшләде, ди.

Барып җитте, ди, бу беренче капкага. Тора, ди, капка төбендә эчләре кипкән, күзләрен кан баскан тау тикле бер үгез. Дию патшасы, ачыгулары җитсә, усалрак булырлар дип, сакчыларын ач тота икән, ди. Үгез үкереп моның өстенә ташланганда, инде изеп бетерә дип торганда, Турай батыр ыргыткан аңа бер йөк печән. Үгез үкерә-үкерә печән ашый калган. Турай батыр эчке якка узган.

Бара торгач, килеп җитә бу икенче капкага. Ташланды, ди, моңа ажгырып торган бер көтү ач эт. Улый-улый киләләр, ди. Инде өзгәләп ата дигәндә, Турай батыр томырды, ди, боларга бер түш ит. Этләр ырылдашып ашый калды, Турай батыр тагын да эчкәрәк юл алды.

Барып җитте, ди, бу өченче капкага, иң хәтәр капкага. Тора, ди, сакта шәп-шәрә бер кеше, кыйнала торгач, тәне җөйләнеп беткән, төсе-чырае киткән, усаллыктан көеп, зәһәрләнеп беткән. Турай батыр моңа өстеннән салып чикмәнен киерткән.

— Мә, туңып торма, кардәш! — дигән.

Сакчы моңа әйткән:

— Әй, яхшы күңелле адәм баласы, гомеремдә беренче тапкыр ягымлы сүз ишеттем. Бар, туган, юлың ак булсын, коткар адәм балаларын,— дигән.

Диюнең сараена барып җитәрәк, моның каршысына бер бите ай, бер бите кояш төсле бер матур кыз йөгереп чыккан.

— Әй, егет,— дигән,— сине нинди рәхимле җилләр ташлады? Көткәнебез син икәнсең. Җиләктәй яшь гомеребез дию кулында әрәм була лабаса. Коткар безне!

Турай батыр, көннәр-төннәр буе йокламыйча килеп, бик арыган икән, кызга әйткән:

— Мин бик ерак илләрдән килгән, арган-йончыган кеше. Диюне җиңәр өчен миңа көч җыярга кирәк.

Кәрлә дию урлап кайткан патша кызлары өчәү икән. Әй тотындылар, ди, болар егетне сыйларга, бөтерелеп кенә йөриләр, ди. Иң башта берсе, эчәсең килгәндер, дип, бер тустаган әйрән салып бирде, аннары казан асып аш салып җибәрде, икенчесе баздан мичкәсе белән ачы бал чыгарды да казылыктыр, фәләндер китереп куйды, иртәгесенә коймак пешерергә дип он или башлады, тагын берсе ак мунчаны ягып җибәрде дә йөгерә-йөгерә инештән су китерергә тотынды.

Турай батыр ашап-эчеп, мунча кереп, өч көн кунак булганнан соң килеп басты, ди, диюнең каршысына. Үзе бер карыш, сакалы биш карыш үзе сәкедә ята, сакалының очын киштәгә элгән дә аны патша кызлары алтын тарак белән тарап торалар, ди.

Турай батыр әйтте, ди:

— Йә, җитте сиңа! Бик күп кан койдың, күп балаларны ятим калдырдың, инде үзеңә дә үләргә вакыт. Алыштанмы, салыштанмы?

Үзе бер карыш, сакалы биш карыш туптай атылып торды да җиңнәрен сызганасызгана әйтте, ди:

— Алыштан да булыр, салыштан да булыр. Әле минем белән көрәшәсе батыр тумаган, туганнары уңмаган. Безнең якта менә болай салалар!

Шулай дип, Турай батырның яңак төбенә берне кундырган икән, егет, аңын җуеп, шундук идәнгә ауган. Дию пәрие, башын өзәм дип, кылычын кыныннан алып, гайрәт белән лаф орып маташканда, әлеге кызлар чыр-чу килеп моңа ябышканда, егет айнып өлгергән.

— Безнең якта алай сукмыйлар, менә болай сугалар! — дигән, диюнең сакалыннан урап алып, болгый-болгый шундый китереп бәргән, дию аяк астында көл булган.

Әй куаныштылар, ди, болар, әй тотындылар, ди, берсен-берсе котларга! Өч көн, өч төн бәйрәм итеп, өч көн, өч төн сәйран итеп күңел ачканнан соң Турай батыр дию патшасының барлык алтын-көмешләрен, асылташларын җыеп кызларны әлеге кое төбенә алып киткән.

Теге ике кызга әйткән:

— Өстә минем ике иптәшем көтеп тора. Алар өйләнмәгән егетләр. Телисез икән, чыккач туй итәрсез. Ә син, чибәркәй, әгәр мине ошатсаң, минем анама килен, миңа хатын булырсың.

Ошатмаган кая инде ул! Теге кыз: «Болай булгач, миңа бигрәк тә батыр егет туры килде әле!» — дип, гел авызын ерып кына тора башлады, ди.

Башта алтын-көмешне чыгардылар, ди. Аннары куркудан чыр-чу килеп, берсе артыннан берсе патша кызлары да менеп киткән. Иң арттан, бауга утырып, Турай батыр

үзе дә кузгалган. Инде чыгып җитәм, инде дөнья яктысын күрәм дигәндә генә бау өзелгән киткән. Турай батыр кое төбенә төшкән киткән.

Әллә ни гомер хәл җыя алмыйча ятканнан соң торган, ди, бу. Инде нишләргә? Алтын-көмеш тагын бер хәл, мал егетне түгел, егет малны таба. Турай батырны иптәшләренең хыянәте бик рәнҗеткән. Аларның әшәкелеге йөрәгенә тоз сипкән.

Тагын әлеге карчыкка барган, ди, бу.

— Әби, дигән, минем юлым уңмады бит әле. Дөньяга чыгарга бүтән берәр әмәл белмисеңме? Белсәң, өйрәтсәнә!

Әби Турай батырны өй артына алып чыккан да болын буена төшә торган бер сукмак күрсәткән:

— Менә шушыннан китсәң, бара торгач, бер су булыр. Шул суның уртасында утрау булыр, анда бик юан, бик учарлы бер карама үсеп утырыр. Шул карама төбендә ике кәҗә тәкәсе күрерсең. Әгәр шул тәкәләрнең агына ябышсаң, дөньяга алып чыгар, инде кара тәкәгә тап буласың икән, ул чагында эшең харап, сак була күр!

Турай батыр, әбигә бик күп рәхмәтләр укып, билен буып, инештә битен юып карчык күрсәткән сукмактан киткән. Көн киткән, төн киткән, өченче көнне төш авышканда бик зур бер су буена барып җиткән. Карый, нәкъ әби әйткәнчә: су уртасындагы утрауда, карама төбендә үгез тикле ике кәҗә тәкәсе сөзешә. Берсе ак, берсе кара. Шундый каты сөзешәләр, утрау дер селкенә, мөгезләреннән яшеннәр атыла.

Ничек кирәк алай утрауга керде бу. Керде дә бу капылт кына ак тәкәнең аягына да ябышты. Ул да түгел, кинәт җил чыккандай, очып киткәндәй булды, дөньялар яктырып китте, ул арада дөп итеп килеп тә төште. Әйбәтләбрәк караса, бу дөньяга килеп чыккан, имеш. Ул арада тәкә дә күздән югалды.

Турай батыр, исән-сау кайтуына бик куанып, өсләрен каккалый да тагын кузгалып китә. Башыннан үткәннәрне уйлап, алдына гына карап килгәндә, юл тузанында эзләр күрә бу. Ике ир кеше, өч хатын-кыз узган. Ул да түгел, ашарга туктаган урыннарында көлгә күмеп калдырган төче күмәчләр дә бар. Шуннан чамалый инде бу: бу күмәчләрне теге чибәр кыз аңарга дип күмеп калдырган була бит инде.

Шул эзләргә басып кайта торгач, бер шәһәргә җитә бу. Карый, шәһәрнең нәкъ уртасында шәп кенә ике йорт салып яталар. Турай батыр сорый шунда:

— Бу йортларны патша салдырамы? Әллә берәр баймы? — дип.

Моңар әйтәләр:

— Юк, патша да салдырмый бу йортларны, шулай ук байлар да түгел: бу яңа йортларны дию патшасын җиңеп кайтучы ике батыр салдыра. Өстәвенә әле патша кызларын да ияртеп кайтканнар.

Турай батыр бу хәбәрне мыегына чорный да, өс-башын алыштырып, соранучы кыяфәтенә керә. Барып керә. Бу барганда тегеләр ашап-эчеп утыралар икән. Моңа да бер сынык икмәк сузганнар. Бу икмәген ашый-ашый тегеләрне күзәтә икән. Теге ике кыз түр башында ук утыралар, ди, моның белән сүз куешкан кыз, башын иеп, бик күңелсез кыяфәттә идәндәге бүкәндә генә утыра, ди. Турай батыр ипиен ашап бетергәннән соң, Ташказар әйтә:

— Йә, сиңа тиешлесен бирделәр бит инде, бар, юлыңда бул!

Турай батыр әйтте, ди, моңар:

— Тарсынма, мин китәрмен, мондый тар күңелле кешеләр янында минем үз күңелем дә тарсына. Тик миңа бик азга гына ук-җәя биреп тормассызмы диебрәк керүем иде.

Тауказар, нишләмәкче була тагын бу хәерче, ди, кызык өчен үз җәясен алырга куша. Турай батыр җәяне тартып караса, җәя чабата шикелле бөгелә дә килә.

Аннан соң икенче иптәше Ташказарның җәясен биреп карыйлар. Турай батыр анысын да тартып кына карый да идәнгә үк ыргыта.

— Хурланмыйча моны күтәреп йөргән ирләрен әйтер идем,— ди.— Белмим, малайшалайга чыпчык куркытып уйнарга гына яраса инде бу,— ди.

Тауказар, кызлар алдында бик хурланып, Турай батырга очынып килде, ди.

— Йә, йә, хәерче, телеңне бик озайтма! — дип җикеренә башлады, ди, тик Турай батырның бүрәнәдәй беләкләренә, үгез муенына күзе төшкәннән соң, тавыш чыгармыйча, шыпырт кына үз урынына китте, ди.

Турай батыр, чөйдә үз җәясен күреп, шуны сорап алган да боларга мондый сорау биргән:

— Монда килгәндә күл буенда биш аккош күрдем,— дигән.— Аларның икесе ата кош, өчесе ана кош. Киңәш бирегезче, шуларның аталарын атыймммы, әллә аналарынмы?!

Кызлар һәммәсе дә ата кошларны атарга киңәш биргәннәр.

— Ана кошларның бала чыгарган чорлары булыр, аларга тимәскә кирәк иде,— диләр.

Тауказар белән Ташказар кызларга каршы төшкәннәр.

— Юк, юк,— диләр,— бетәсе булгач, барысы да бетсен. Нигә аталарын гына аерып атарга? Аларның ни гаебе бар?

Бу сүзләрне ишеткәч, Турай батыр идән уртасына килеп баса да, җәясен тартып, угын батырларга төби.

— Гаепләре бар шул,— ди.— Аккош бервакытта да сыңар-сыңар йөрми ул. Сез миннән: «Нигә биш кенә, нигә алты түгел?» — дип сорамадыгыз. Алайса үзем әйтим. Бер ата кошны теге икесе, үлсен дип, ярты юлда чукып-чукып тинтерәтеп, аерып калдырдылар. Шулмы булды иптәшлек, шулмы булды егетлек?

Моны ишеткән батырлар коелып төшкәннәр.

Аннан соң Турай батыр теге ике кыздан сораган:

— Бу ике аккош үләргә тиешме, әллә калыргамы?

Кызлар икесе бердән әйткәннәр:

— Үләргә тиешләр.

Шуннан соң Турай батыр әйтә:

— Алайса, мә, Ташказар, ал өлешеңне! Мә, Тауказар, сиңа да!

Берәр көннән Турай батыр теге ике кызны салынып яткан ике йортка кертеп, аларга бик күп алтын-көмеш калдырып, сүз куешкан кызы белән анасы янына кайтып китә. Авылына кайтып җитү белән туй итә башлыйлар.

Бүген бардым, кичә кайттым. Мин дә булдым ул туйда. Сый-хөрмәт бик дан булды, ашатканнары ит тә май, эчерткәннәре бал булды. Ике мичкә, бер чүмеч, теләсәң күпме эч. Тик үзләре чүмеч белән эчтеләр, безгә сабы гына эләкте.

ЧУРА БАТЫР

Әүвәл заман бар икән,
Чура Батыр ир икән,
Ил эчендә бер икән,
Яу кайтарыр ир икән.
Бүз кыр дигән җирендә
Ат утлатып йөргәндә
Дошман килә далага.
Казан каласын алмага.
Моны белгәч Чурабыз
Кылычын биленә тагадыр,
Ук-садагын асадыр,
Казан юлына чабадыр.
Бер дөлдөлдәй оча икән
Чал атында чапканда,
Кыя-ташны яра икән
Аткычыннан атканда.
Кулмәгенә ук тисә,
«Яңгыр ява»,— ди икән.
Чигәсенә ук тисә,
«Чебен тешли»,— ди икән.
Чигәсеннән кан чыкса,
«Тирем чыга»,— ди икән.
Җилкәсеннән кан чыкса,
«Җилләр исә»,— ди икән.
Чура Батыр ир икән,
Менгән аты бер дигән.
Илгә килгән яуларга
Каршы чыгар ир икән.

Менә шулай итеп, мин сезгә Чура Батыр хикәятен сөйләмәкче булам. Әмма әйтеп куям, бу бер әкият түгел, үткән заманнарда булып үткән бер мисалдыр. Борынгылар, булмаган булса, әйтелмәс, сөйләнмәс иде дип юкка әйтмәгәннәр.

Әйтәчәгем шул, әүвәл заманда бер хан булган, ди. Аның утыз тугыз хезмәткәре бар икән. Боларның өстендә дә кырыгынчысы — Нарык атлы берсе — баш хезмәткәр икән.

Көннәрнең берендә хан үзенең бер вәзире белән йөрергә чыга. Сарай бакчасында сәйранда йөргәндә Нарыкның алар яныннан баш иеп, сәлам биреп үткәнен күрә дә хан вәзиренә әйтә:

— Бу Нарык бик тырыш һәм бик тугры бер кеше. Кызганыч, шул яшенә җитеп тә өйләнмәгән, дуадак каз кебек йөри. Аны бик өйләндерәсем, башлы-күзле итәсем килә,— ди. Бераз уйланып торгач, соңра әйтә: — Вәзир, иртәгә Нарык бер алашаны иярләсен, син дә иярлә бер алаша; китегез дә мәмләкәтемне гизегез. Кемнең кызын беренче күрәсез, аны алдырырмын,— дип әмер бирә.

Иртәгәсе көнне вәзир иртән иртә тора да Нарыкны чакыртып:

— Иярлә бер алаша үзеңә, тагын берсен миңа,— дип боера.

Менәләр атларына, китәләр болар. Ахшам була, кич җитә, баралар бер көйгә. Кунып калалар. Иртән торалар да тагын юлга чыгалар. Баралар, баралар, әңгер-меңгер төшә башлаганда тагын бер җиргә барып җитәләр. Монда тагын бер кичне кунып калалар болар. Иртәгәсе көнне иртүк торып, атларына атланып юлга чыгалар. Шулай итеп, өйдән-өйгә, кырдан-кырга, җирдән-җиргә көн китәләр, ай китәләр, ил гизеп йөриләр. Көннәрнең берсендә, һичбернәрсәдән хәбәре булмаган Нарык, вәзиргә карап:

— Вәзирем, без үзбашына нишләп йөрибез соң? — дип сорый.

— Ханыбыз сине өйләндерергә тели. Барыгыз, Нарык белән мәмләкәтне гизегез дә аңа бер кыз табыгыз дип әмер бирде.

— Алай булса, без юкка интегеп йөрмик. Ханның әмере бу булса, каланың кырыендагы аулак бер өйдә ялгыз үскән, үксез бер кыз бар. Аны миңа алып бирсә, бик куанырмын,— ди Нарык.

Моны ишеткәннән соң вәзир белән Нарык калага кайтып китәләр. Вәзир, хан янына барып, Нарыкның ниятен белдерә. Ханның әмере белән кырык көн уен итеп, кырык көн туен итеп кызны Нарыкка алып бирәләр.

Шул көнгәчә, бу кыз бик фәкыйрь, ямаулы әйберләр генә киеп йөргәнгә аңа беркем дә борылып карамаган булган икән. Шул ямаулар эчендә гүзәл бер кыз сакланганы берәүнең дә башына килмәгән.

Чыннан да, бу кыз шундый гүзәл икән ки, буе тал чыбыгыдай зифа, йөзе айның ундүртенче кичәседәй, кара кашлары карлыгач канатыдай, ике яңагы яңа ачылган ике гөлдәй, күзләреннән дә шөйлә нурлар агып тора икән. Кызның туе булып ятканда гына аның шундый гүзәл икәнлеген күреп, ханның асрамага алган улы — мирзаның күзе төшә.

Вакытлар уза тора. Көннәр үтә, айлар үтә, алты ай тула. Нарыкның өендә ут сүнми. Аның тәрәзәсе каршында гына бер өй бар икән. Анда ханның ат караучысы яши икән. Ат караучы да хан улының гелән-гелән «хәл белешергә кердем әле» дип килеп йөрүенең бер сылтау икәнен, асылда исә Нарыкның хатынын күрмәгә килүен аңлап ала. Көннәрнең берендә мирза шулай сылтау белән каранып йөргәндә, ат караучы аңа якын килеп:

— Мирзам, туктап тыңлачы, сиңа бер сүзем бар,— ди.

— Ни ул, яхшы сүзме, яманмы? — дип сорый мирза.

— Яхшымы-яманмы, белмим, мирзам, менә мин бу көнгәчә гаҗәпкә калдым әле.

— Ни өчен икән, йә, әйт, тыңлыйм,— ди мирза.

— Мынау, сезнең Нарыкның туе булганына алты айдыр инде, әмма өендә ут сүнгәнен

күргәнем юк. Кичә бардым да тәрәзәсеннән карадым. Тәрәзәнең бер чите ачык калган иде. Хатыны түшәктә ятыр иде. Үзенең йөзеннән нур бөркелә, әстәгъфирулла! Миңа калса, бу хатын бер дә Нарыкка лаек түгел,— ди.

— Алай булса, аны ничек аерып алырга соң? — дип сорый мирза.

— Нарык сезнең колыгыз түгелме? Бер хат язып тоттыр да җибәр аны бер ерак җиргә. Тиз генә кайтырлык булмасын. Хатын-кызны «чәче озын, акылы кыска» диләр. Нарык кайтып килгәнче берәр чарасын күрерсең! — ди.

Мирза бер сүз дә әйтми, уйланып тора да сараена кайтып китә. Кайтып җитүгә Нарыкны чакыртып ала. Аңа:

— Нарык, иярлә бер ат! Күрше мәмләкәтнең ханына бер мәктүп алып китәчәксең. Кайтканда Каф тавына барып миңа бер иярлек каурый агач алып кайтырсың,— ди.

Нарык ат иярләргә утарга китеп бара. Мирза да мәктүбен язарга утыра. Язып бетергәннән соң барып Нарыкка бирә дә:

— Сак бул, тиз кайтамын дип бәла-казага очрама. Яхшы кәеф белән кит, яхшы кәеф белән кил, кайтырга ашыкма! — дип нәсыйхәт бирә.

Нарык мәктүпне алып атына атлана да юлга чыга. Китеп барып ятканда гына башына уй төшә моның: «Мин китеп барам, ә хатынымның бернәрсәдән хәбәре юк. Өйгә кайтыйм да аңа кайда китеп барганымны әйтием. Аның да хәбәре булсын. Миңа да исән-сау йөреп кайтырга язсын»,— ди.

Ди дә, атын кире борып, кайтырга чыга. Өенә кереп хатынына:

— Мине өч-дүрт көн көтмә! — ди дә кайда һәм ни өчен барганын аңлатып бирә.

Хатыны бераз уйланып тора да:

— Син китсәң кит, әмма иртәгә өйләдән соң сәгать ике-өчләрдә кайтып, иллә бер кире килеп өйгә күз сал! — ди.

Шуннан соң Нарык юлга чыга. Үзе юлда бара, үзен һаман бер сорау борчый, күңелен шөбһә ала: «Ай, анакаччаем! Ни өчен хатыным миңа шулай диде икән?! Үзем дә ерак бер җиргә китеп барам. Нәрсә булса да булыр, иртәгә кайтып килеп өемне күрим, күз-колак булыйм әле»,— ди.

Башына мондый уй килгән җире дә бик аулак бер урын икән. Бара да ята бер чирәмлеккә. Иртән тора. Сәгать ике-өч мәлләрендә өенә кайтып килә дә атын абзарга кертеп бәйли. Өенең тәрәзәсе каршына килеп эчкәрегә карый. Караса, ни күрсен! Эчтә ханның асрау улы утыра. Хатынына нәрсәдер сөйләргә, аңлатырга маташа бу. Анисы мирзаның лаф оруын кабул итми, кире кага. Бер мәлне мирза бер җанвар, вәхши хайвандай хатынына ябыша, намусына тап төшермәк өчен зар итә башлый. Хатыны исә кычкырырга, ярдәмгә чакырырга керешә. Моны күреп, Нарык тыелып тора алмый, тәрәзәгә чиртә. Хатыны, мирзаның тимердәй кулларыннан котылып, йөгереп барып ишекне ача. Мирза котырган эттәй нишләргә белми, оятка чыга инде. Нарык та оятка кереп, ишек артындагы балтаны алып, шул балта белән мирзаның башын чабып ала.

— Инде моны нишләтик? — дип сорый Нарык хатыныннан.

— Нишләтик соң?.. Алып кит тә күм аны тирескә! — ди.

Нарык, мирзаны сөйрәп алып, хатыны әйткәнчә абзардагы тирескә күмә. Үзе, аннан соң, атына атланып, мирзаның мәктүбен илтер өчен юлга чыга.

Бер көн үтә, ике көн үтә, карыйлар, мирза юк булган! Хан вәзирләрен чакырып алардан:

— Безнең мирзабыз кая булды. Берәр нәрсә сизмәдегезме? — дип сорый.

— Юк, ханым. Синнән рөхсәтсез бер җиргә дә китмәс иде,— дип җавап бирәләр.

Хан вәзирләренең берсе бик белемле икән. Ул:

— Ханым! Илеңдә никадәр кеше булса, һәммәсен чакырып, сораштырып күздән кичерик,— ди.

Илнең һәр ягына чапкыннар җибәреп, һәр кешене вәзирнең каршысына чакыралар. Вәзир аларның һәммәсеннән:

— Ханның улы мирзаны күрмәдегезме? — дип сораштыра. Ләкин «күрдек, белдек» дигән бер кеше дә чыкмый. «Тагын кайда кем бар икән?» дип уйланып торганда, вәзир:

— Синең тагын утыз тугыз хезмәткәрең бар, аларны да чакырып сораштырыйк,— ди.

Аларны да чакырталар. Һәммәсе киләләр. Алар арасыннан да «күрдем, белдем» дигән берәү дә чыкмый.

— Тагы кем калды? — дип уйланып торганда:

— Бер Нарык калды,— дигән җавап алалар.

— Чакырыгыз Нарыкны да, аннан да сорыйк,— диләр.

Шуннан Нарыкны да чакырталар. Ул ишектән кергәндә үк вәзир, аның үтергәнен тоеп, турыдан-туры:

— Нарык, мирзаны нишләттең? — дип сорый.

— Үтердем,— дип җавап бирә Нарык.

— Соң, ни сәбәп белән үтердең аны? — дип сорый вәзир.

— Беркөн иртән сарай абзарында йөри идем. Мирзам мине катына чакырып алды да: «Нарык, иярлә атыңны, күрше мәмләкәтнең ханына бер мәктүп апкитәрсең»,— дип әйтте. Мин атымны иярләмәгә башладым, мирзам чыкты мәктүпне алып. Алдым мәктүпне, мендем атыма, чыктым юлга. Китеп барган җиремдә башыма уй төште. «Ай, анакаччаем! Мин алҗыган кешедәй өемә хәбәр-мәбәр итмәстән кайда китеп барам соң әле! Кайтыем да өемә кереп кайда китеп барганымны хәбәр итәем, саулык белән кайт дигән теләкләрне ишетәем»,— дидем. Юлдан кире кайтып өемә кердем дә хатыныма: «Мин ерак бер җиргә китеп барам, мине өч-дүрт көн көтмә!» — дидем. Ул да миңа: «Китсәң кит, әмма иртәгә сәгать ике-өчләрдә кайтып өйне белеш»,— дип әйтте. Соңра, саулык белән кайт дигән теләкләрен ишетеп, атыма атландым да чыгып киттем. Үзем китеп барам, әмма шунда башымны бер уй алды. «Ай, анакаччаем,— дидем мин үз-үземә.— Гаҗәп, бу минем хатыным ни өчен, иртәгә сәгать ике-өчләрдә кайтып өйгә күз сал әле, дип әйтте соң? Бу кадәр ерак җирдән ничек кенә кайта алырмын?» Ул чакта аулак бер җирдә идем. Атымнан сикереп төштем, җибәрдем атымны утларга, үзем исә чирәмлеккә сузылып яттым. Хатынымның әйткән сүзләрен уйлый-уйлый йоклап киткәнмен. Икенче көнне иртән бер мәлдә уянсам, тагын үз-үземә уйлана башладым. Сикереп мендем атыма, өемә кайтып киттем. Атымны бәйләдем абзарга, үзем исә хатыныма берни сиздерми абзарның бер почмагында качып утырдым. Сәгать ике-өч тирәләре җитте. Мирза караучысыз калган өемнең ишегенә килеп хатыныма: «Ач ишегеңне!» — дип аваз салды. Мин генә бер сүз әйтмәй посып утырамын. Ул аваз сала, хатыным ачмый. Ул тагын аваз сала, тавышлана, хатыным исә: «Ачмаем!» — дип, эчкәредән җавап бирә. Шуннан соң ул ишекне каерып ачып эчкә кереп китте. Мин торып тәрәзәнең ачык калган бер почмагыннан: «Карыйм әле, моның нияте нидә икән?» — дип, карап тордым. Мирза аягөсте, хатыным ятып тора, аңа лаф ора. Хатыным кабул итми. Соңра, бер җанвардай сикереп, хатыныма ташланмакчы итә. Тыелып тора алмадым. Чиерттем тәрәзәне. Хатыным йөгереп килеп ишекне ачты. Мирза да

ояткa чыкты. Мин дә ояткa кердем. Ишек артындагы балтаны алып шуның белән кистем дә алдым башын»,— дип Нарык аңлатканнан соңра, вәзир:

— Аны кая куйдың инде? — дип сорый.

— Хатынымның «алып кит моны да күм тирескә» дип әйткәненчә, алып киттем, күмдем аны абзардагы тирескә,— ди Нарык.

Бу мәмләкәтнең ханы бик тугры кеше икән, гадел хөкемдар икән. Үзенең асрау улының ясаган гаделсезлекләрен Нарык авызыннан ишетеп бетерүгә, хан тора да:

— Алайса кабахәтлек минем баламда икән,— ди. Соңра Нарыкка күз яше белән карап тора да әйтә: — Шулай да бүгеннән күземә күренмә! Ике ат, бер арба бирәмен. Йорт-җиреңне, мал-мөлкәтеңне төя дә хатыныңны ал да чыгып кит, башка мәмләкәттә яшә. Монда калсаң, сине күргән саен балам күз алдыма киләчәк. Минем бу сүзләрем көчендә кала. Әйдә, тиз югал күз каршымнан! — дип хөкем итә.

Нарык икенче көнне иртә белән тора. Арбасына, үзе белән алып китәчәк хезмәткәрен һәм йөкле хатынын янына утырта да юлга чыгып китә.

Бер җай белән баралар да баралар болар, бермәлдән күз аллары караңгыланып, кич җитә. Ул көнне юлда калалар. Хатыны бер төш күрә: имеш, бер су агып бара да ут булып яна башлый. Соңрак яңгыр килеп бу утны сүндерә, имеш. Иртән торуга ук хатыны Нарыкка әйтә:

— Бездән бер углан туачак, атыш уты булып яначак, әҗәле исә судан булачак,— ди.

Чыннан да, хатыны авырга узган икән, ягъни авыраяклы икән. Беркөн, шулай итеп, юлда китеп ятканда Алланың рәхмәте илә хатын бер угыл бала таба. Баланы юарга сулары булмый. Нарык арбадан төшеп су эзләргә керешә. Эзли-эзли, бер хайван тоягыннан калган чокырда аз гына су таба. Баласын кочагына алып шул җиргә алып китә дә аны шул су белән юа башлый. Башлый, әмма баласының бер үкчәсе ялгыш җиргә тиеп китә. Бала үкчәсе тигән җирдән кинәт, Алла рәхмәте белән, саркылып су чыга башлый. Баланы чип-чиста итеп юалар. Яннарында чүпрәкләре булмаганлыктан, арба эчендәге йонга урап биләүлиләр. Нарык бик куана, баласын карап-карап туя алмый: «Батыр балам, батыр, йон ябынып ятыр! — ди дә,— улымның исеме Чура булсын, батыр булсын»,— ди. Аннан соң үзләре дә барып, һәммәсе шул суда юынып, чистарыналар. Җиңеләеп киткәч, арбаларына менеп утыралар да юлларын дәвам иттерәләр. Бара торгач, көннәрнең берендә кеше яши торган бер җиргә барып җитәләр. Баралар да бер ихата капкасын кагып:

— Без Алла мөсафиры, кертәсезме, юкмы? — диләр.

Ул өйнең хуҗасы бик ачык күңелле, юмарт кеше икән.

— Хуш килдегез, боерыгыз,— дип, ихатаның күршесендәге өйнең ишеген күрсәтә дә: — Керегез, минә бу өй буш, сезнеке булсын,— ди.

Нарык бу хуҗаның өендә бер-ике көн кунганнан соң, өченче көнне китәргә булып, арбасын төяргә тотына. Хуҗа кеше исә мәчеткә намаз укырга киткән икән. Кайтып керсә, ни күрсен! Нарыкның арба төяп ятканын күрә дә:

— Нарык, кардәшем, син нишләргә җыенасың? — дип сорый.

— Әй, хуҗакаем! Бер көн мөсафир, ике көн мөсафир, өченче көнне кит кяфер, диярләр. Ике көн буе диярлек ашап-эчеп яттык, Алла сиңа бәрәкәт бирсен, сау булыгыз! Инде китеп үз бәхетебезне үзебез табып карарга исәп,— ди.

— Кая китәсең, кардәшем? Моннан да яхшы урын таба алырсың микән, ай. Утыр, кал монда! Син торган шушы өй сиңа анамның сөтеннән хәләл булсын! Яшь балаң бар, аның белән кая китәрсең? — ди.

— Сау бул, хуҗакаем, никадәр теләсәм дә кала алмам. Кала алмыйм. Минем монда җырләшкәнемне ишетә калса, хан кешеләрен җибәрер дә сине җәзага тартыр,— ди.

— Кайсы хан, кардәшем? Бу җир син курыккан Казан ханының туфрагы түгел. Аның монда һөҗүме җитмәс. Бу — Кырым ханлыгына буйсынган бер туфрактыр. Шулай булгач, син һич курыкма. Әнә абзар тулы малым бар. Сиңа бер сыер да бирермен. Сау да сөтен эч. Син дә миңа мал караганда күз-колак булышырсың. Аркадашың өй эчендә ярдәм итәр,— ди.

Шулай итеп, Нарык бу хуҗаның өендә куана-куана яшәп кала. Бик тырыш һәм бик тәртипле Нарыкны хуҗа кеше дә үзенең кан кардәшедәй күреп ярата икән.

Көннәр, айлар, еллар судай агып китә тора. Чура да бик тапкыр һәм үткен, батыр һәм куркусыз бала булып җитешә. Ул заманнарда бозауларны көтәргә аерым бер кеше булмаганлыктан, аларны балалар бага икән. Чура да үзенең бердәнбер бозавын хуҗаның бозауларына кушып, башка балалар белән бозау көтәргә йөри башлаган. Бер җомга көнне төш вакытында балалар болында бозау карап, ашыт уйнап утырган вакытта, тайлы биягә атланган суфый кыяфәтле бер кеше килеп чыга да сорый:

— Мин бер Алла мөсафирымын. Яныгызга аласызмы-юкмы? — ди.

— Хуш килдең, суфыйкаем, боерыгыз,— ди Чура.

Аннан соң йөгереп барып балаларның таякларын җыеп ала, аларның башларын бер-берсенә бәйләп чатыр сыман нәрсә әмәлләп куя, өстен ябып, күләгәлек ясый.

— Боерыгыз, суфый агам! Ертылып, тетелеп беткәнсегез! Менә бу күләгәлек астында ятып бераз хәл җыегыз,— ди.

— Сау бул, улым! Син бик тәрбияле бер бала икәнсең,— дип, суфый күләгәлеккә кереп ята. Чура бөтен балаларны җыеп ала:

— Безгә Алла мөсафиры килде! Үзем күрдем, бик-бик ерак җирдән килә. Аны сыйларга, тамагын туйдырырга кирәк.— Аннан бер балага: — Синең ун баш бозавың бар, аның берсен суйыйк та суфый агайга бирик, сыйлыйк,— ди.

— Мин әтиемнән куркам шул,— ди ул бала.

Тагын икенче бер балага әйтеп карый.Ул да риза булмый. Тота да үзенең мал исәбендә йөргән бердәнбер бозавын суя. Бер аркадашын казан асып учак тергезмәгә җибәрә. Үзе бозауның тиресен туный башлый. Инде тунап бетердем генә дигәндә, балалар да казан, учак алып килеп җитәләр. Бозауның башын парлап казанга салалар, түшеннән дә кисәк-кисәк ит алып кыздыралар. Шулпа белән кыздырылган ит әзер булганнан соң арып-талып йокыга киткән суфый да уяна. Чура аның янына барып:

— Суфый агам, боерыгыз табынга, хуш килдегез! — дип, табын янына чакыра. Бөтен балалар суфый агай белән бергәләп табын янына утыралар. Карыннарын туйдыргач, суфый бер дога укый да:

— Мине сыйлаганыгыз өчен бик зур рәхмәт сезгә, сау булыгыз! Юл юлчыга ярашыр, юлчы да юлга ярашыр, диярләр. Мин дә юлымны караем инде. Менә бу якта бер авыл бар, анда да минем Нарык дигән бер якын аркадашым бар, мин аның янына ашыгамын,— ди.

— Алайса, суфый агам, авырсынмасаң, бу бозауның итен атыңа салыйм, алып кит аны да әтиемә бир, ахшамда сине сыйлар. Ул Нарык дигәнең минем атам булыр,— ди Чура.

— Бик яхшы, улым. Сал, алып китәрмен,— ди суфый агай.

Шуннан соң Чура бозау итен суфый агайның атына бәйли. Инде китәм дип атына менәргә торганда гына суфый ага, балаларга борылып:

— Әй, балалар, сезгә бер уен өйрәтимме,— дип сорый.

— Өйрәт, суфый агай, өйрәт,— дип кычкырыша балалар.

— Менә мин билемдәге шушы кылычымны җиргә кадыйм. Сез ераккарак китеп артыгыз белән әйләнеп торыгыз. Мин «Әйләнегез!» дигәндә иң беренче булып кайсыгыз шул кылыч өстенә килеп ята, кылыч белән шушы тай аныкы булыр,— ди.

Балалар читкәрәк китеп артлары белән әйләнеп торалар. Суфый агай исә, кылычын киеме эченә яшереп, аның урынына бер таяк кадый, өстенә чүпрәк ябып куя. «Әйләнегез!» дигәч, балалар әйләнеп, йөгереп килеп чүпрәк өстенә ятмакчы булалар. Киләләр, әмма һәркайсы куркып туктап кала. Садә Чура гына бернәрсәдән курыкмый, йөгереп килеп чүпрәк өстенә каплана.

— Афәрин, Чурам! Булырдай бала ...нан билгеле, диләр. Син батыр булачаксың. Бу кылыч белән тай синеке булсын, алар синекедер. Кызганыч, әле син бик яшьсең. Вакыты, заманы җиткәч, мин аларны сиңа китереп бирермен. Хәзергә саулык белән калыгыз,— ди дә атына сикереп менеп китеп тә бара.

Китә-китә, ахшам җитәрәк Нарыкның өенә килеп җитә.

— Нарык, Нарык,— дип кычкыра башлый.

Нарык карый, каршысында таныган да шикелле, танымаган да шикелле бер кеше тора. Кем икәнлеген белә алмаса да:

— Боер, кер эчкәре! Хуш килдең!..— ди.

Нарык суфыйны эчкә алып керә. Утыралар. Бер-берсеннән исәнлек-саулык сорашканнан соң суфый әйтә Нарыкка:

— Мин бүген гаҗәпкә калдым әле,— ди.

— Хәерлегәме? Ни булды?

— Хәерлегә, хәерлегә,— ди суфый.— Монда килер алдыннан болында бер төркем балаларның бозау көтеп йөргәннәренә тап булдым. Аларга: «Алла мөсафирымын, яныгызга аласызмы?» — дидем.

— Алла мөсафирын кем алмас икән, ай,— ди Нарык.

— Шул балаларның арасында бер кечкенәсе бар иде. Йөгереп балаларның таякларын җыйды, бер башларыннан бәйләп миңа куләгәлек корды. Өстенә бер чүпрәк япты, астына да чүпрәк түшәп: «Суфый агам, боер, кер эчкәре»,— диде. Эчкә кердем. Бу бала тышка чыгып балаларны җыйды да: «Безгә Алла мөсафиры килде, бер бозауны суеп, аны сыйлыйк»,— диде. Балаларның һәрберсе: «Атабыздан куркабыз!» — диделәр. Теге баланың үзенең бердәнбер бозавы бар икән. Шуны суйды, балаларны казан, учак алып килергә җибәрде. Үзе исә бозауны тунарга кереште. Шул арада балалар учак, казан алып килеп җиткерделәр. Бозауның башын парлап казанга салдылар. Итен дә кисәккисәк итеп күмер өстендә кыздырдылар. Шуны миңа бирделәр. Һәммәбез утырышып ашадык, карыныбызны туйдырдык.— Аннан Нарыкка карап,— ай, Нарык, ул синең улың икән. Әнә бозауның итен ат өстенә салып сезгә җибәрде,— ди.

Нарык белән хатыны барып итне алалар. Кисәк-кисәк итеп турыйлар да казан асалар.

Суфый:

— Ай, Нарык, минем өчен казан асып мәшәкатьләнмәгез. Мин синең белән бер күрешеп танышыр өчен генә килдем,— ди.

Нарык белән хатыны:

— Кун бездә, суфый ага,— дип ялварсалар да:

— Булмас, мин инде китием. Саулык белән калыгыз,— ди дә суфый ага кунмый, атына менеп чыгып китә.

Шул арада болыннан Чура да кайтып керә:

— Әти, әти,— дип кычкыра башлый.

— Ни бар? — ди Нарык.

— Монда бер суфый ага килдеме? — дип сорый Чура.— Мин аңа бозауны суеп, итен сезгә җибәргән идем.

— Килде, улым, килде. Бик ару иткәнсең,— ди дә барып Чураны кочаклап сөя башлый.

Көн артыннан көн куа, ай артыннан ай куа, диләр. Еллар үтә. Нарык, хәлле генә кешегә әйләнеп, мал-мөлкәт туплап алганнан соң, авылны ташлап: «Ни булыр да ни булмас, мәмләкәтемә якынрак булыйм»,— дип, Көкешле Тамга дигән бер каланың кырыенда өй салып, барып урнаша. Чура да ундүрт-унбиш яшьләренә җиткән була. Көннәрнең берендә суфый агай, менгән атына бәйләп, гүзәл бер дөлдөлгә охшаган таен ияртеп килә:

— Нарык, Нарык! Чура өйдәме? — дип кычкыра.

— Боер, суфый агам, өйдәдер, әйдә, кер,— дип чакырган Нарыкка суфый ага:

— Әйт Чурага, миңа бер тасма китерсен,— ди.

Чура өйдән бер тасма алып чыгып суфый агага бирә.

— Менә, улым! Син инде вакыты-кимәленә кердең. Ал, сиңа әманәтеңне китердем,— ди.

Чура куана-куана тасманы алып гүзәл тайның муенына бәйли дә:

— Моның исеме Тасмагер булсын! — ди. Аннан соң суфый ага кылычын чыгарып Чураның биленә бәйли дә:

— Инде, улым, эш курыкмауда. Җаның кайсы якка теләсә, шул якка китә белерсең! — дип, аркасыннан кагып, сөеп куя. Шуннан соң ул:

— Саулык белән калыгыз! — дип, атына атлана да күздән югала. Аны яңадан һич күргәннәре булмый.

Суфый агай киткәннән соң гаскәрилеккә язып йөри башлыйлар. Чура әтисе янына килә дә:

— Әтием, мин дә гаскәрилеккә язылыймчы,— дип ялвара башлый.

— Сиңа вакыты җитмәде әле, улым. Вакыты-заманы килгәндә сине калдырмаслар,— ди атасы.

Чура әтисенең әйткәннәренә риза булмый:

— Китәмен дә китәмен! — дип зар итә.

— Алайса, балам, китсәң китәрсең, тагы, кайтырсың. Бар, кит, юлың ачык булсын! — ди атасы.

Чура, куанып, араннан Тасмагер атлы таен чыгара, яхшылап иярли. Аннан соң уксадагын, аткычын алып нәнәсе әзерләгән биштәргә азык-төлек салып муенына элә, суфый ага биргән кылычны биленә тага да атына сикереп менә:

— Саулык белән калыгыз! Алар мине гаскәрилеккә язарга теләмәде, мин үзем кирәк җирен табармын! — дип чыгып та китә.

Китә-китә, ахшам өстендә бер гаскәрия кышлавына барып җитә. Кышлауның бер ягында бәйләр яңа алынган гаскәриләрне карап, өйрәтеп утыралар икән. Чура аларның янына барып:

— Әссәламәгаләйкем! — ди.

Бәйләр арасыннан Чураны таныган берсе:

— Син нишләп йөрисең, Чурам? Кая барасың, улым? — дип сорый.

— Гаскәрилеккә язылырга килдем, бәй агам! — дип җавап бирә Чура.

— Ай-һай, улым, син бик яшьсең бит әле,— ди таныш бәй.

— Яшь булсам да, сынатмам, карап карагыз, җиңәрмен,— ди.

— Алай булса, карап карыйк! Сынап карыйк сине! — ди бәйләрнең берсе.— Аткычың-җәяңне кулыңа ал да ат шуннан угың белән кышлауның әнә теге башындагы казыкка,— ди.

Чура аткычыннан угын ычкындырып җибәрүе була, ук, казыкны тишеп, аның артындагы кыяташка барып бәрелә, аны икегә ярып ташлый. Моны күргән бәйләрнең арасыннан берсе — Акташлы Али бәй дигән берәүнең йөрәге жу итеп китә. Чөнки инде күптән аңа бер фалчы: «Кара, сак бул, Чура дигән берәү туачак, бик батыр бер егет җитешәчәк. Син шул Чура Батырның кулыннан үләчәксең!» — дигән булган икән. «Чыннан да шушы булырмы икәнни?» — ди, үз-үзенә. Эченә бер шик, курку төшә. «Ничек котылыйм икән моннан?» — дип, кичен-көндезен уйлана, борчыла. Чурадан котылу чарасын эзли башлый.

Шулай итеп, тагын бер кыш, бер ел үтеп китә. Чыннан да, Чура бик батыр бер егет булып җитешә. Аның исеме барлык ханлыкларга җилдән дә җитез хәбәр булып барып ирешә.

Көннәрнең берендә Чура Батыр ата-анасын, кыз кардәше Канибәкне һәм балалыкта уйнашып-көлешеп үскән Алтын атлы кызны бик сагына башлый. Бәйләрнең янына бара да:

— Бәй агаларым,— ди,— мин ата-анамны, туып-үскән җирләремне бик сагындым. Мөмкин булса, сездән рөхсәт сорарга килдем,— дип, бәйләрдән бер айлык ял алып китә.

Чура китә торсын. Акташлының Али бәе үзенең гаскәри егетләреннән берничәсен чакырып ала да аларга:

— Чураның алдына чыгыгыз! Сүгегез, ачуын китерегез, сүз дә әйттерми аны юлыннан кире кайтарыгыз. Бер ул гына сезнең каршыгызда батыр булып кыланмасын, акыл сатмасын әле. Өйрәтик әле үзен,— ди дә Чураның артыннан җибәрә. Акташлы Али бәйнең гаскәрләре юлны кистереп чыгып, атларын чаптырып Чура Батыр үтәчәк бер борылышта посып утыралар. Бераздан Чура Батыр күренә. Ул:

Ай, туган җир, туган җир,
Ата-анам торган җир,
Чик буенда ике ханга
Казык булып торган җир.
Тугайлары түшәктәй,
Иркен дала бишектәй,
Уйнап-көлеп үскән җирем,
Онытылмассың ничек тә,

дип җырлый-җырлый үтеп бара икән. Али бәйнең гаскәрләре кинәт сикереп чыгалар да Чура Батырга: «Тукта!» — дип кычкыралар, ул туктамый. «Кайт кире!» — диләр, ул кайтмый. Аннан соң аны яман-яман сүзләр белән сүгәргә, котыртырга тотыналар. Чура Батыр колак та салмый юлын дәвам иттерә. Атларына атланып, Чура Батырны куып җитәләр, аны сарып алалар. Чура Батыр көмештәй кылычын кынынна суырып чыга-

ра да ун гаскәридән тугызының башын чабып ала. Унынчысының җилкәсеннән эләктерә дә:

— Сезне кем җибәрде? Әйтмәсәң, синең дә башыңны кисеп төшерермен,— ди.

— Безне Акташлы Али бәй җибәрде, аның кешеләре без,— дип җавап бирә куркуыннан дер-дер калтыранган гаскәри.

— Сине гафу итәм, әмма тагын бер каршыма чыкканыңны күрмим. Бар, кит, Акташлы Али бәеңә күргәннәреңне әйт. Бүгеннән соң минем каршыма сезнең кеби чапкыннарын җибәрмәсен! Әгәр ул сездәй этләрен тыя алмаса, мин тыя белермен! — ди дә гаскәрине кайтарып җибәрә. Үзе исә Тасмагерына атланып яңадан җырлый-җырлый туган якларына юл тота.

Мәсхәрә ителгән гаскәри, Али бәйгә кайтып, күргәннәрен, булып узган хәлләрне түкми-чәчми, бәйнә-бәйнә сөйләп бирә, Чура Батырның «сәламен» җиткерә. Боларны ишеткәч, Али бәйнең йөрәген тагын бер кат курку биләп ала: «Чура Батыр чыгачак», диләр иде. Алайса Чура Батыр шушы икән. Моны вакыты җитмәс борын, берәр сылтау табып үтерергә кирәк»,— ди. Икенче көнне, гаскәрине янына алып, Кырымның ханы янына йөгерә. Ике арага фетнә тыкмак өчен болай дип сөйли башлый:

— Сөекле ханым! Тиңдәшсез Казан ханының улын үтереп, синнән сорамый-нитми, синең ханлыгыңның сынырына (чик буе өлкәсе) Көкешле Тамгага Казан ханлыгыннан качып килеп, Нарык атлы бер хаин килмешәк күчеп утырган. Килгәненә инде ун елдан артык булуга карамастан, мәмләкәт казнасына берни бирми, малын-мөлкәтен утлатып гаиләсе белән үзбашына аерым яшәп ята дип ишеттем. «Хаиннан хаин туар» диләр. Бу килмешәкнең үзенә охшаган Чура атлы бер улы бар. Колагыңа чалынганы бардыр. Бик дуамал, чапкын бер егет. Беркемне дә тыңламый, буйсынмый. Бу егет кышлауга килеп гаскәр җыя башлаганнан бирле коткы тарата, кышлаудагы гаскәриләр бөекләрнең сүзләрен тыңламый башлады. Һәммәсе аның артыннан иярә, баш күтәрергә әвәсләнделәр. Менә, төнәген (кичә) минем ун гаскәриемнән тугызының башын чабып ала да, унынчысын исән калдырып, аның аша миңа куркыту-янау катыш сәламнәр җибәргән. Ышанмасаң, үзең ул гаскәрине чакыртып, Чураның ниләр әйткәнен сораштырып карый аласың,— ди.

— И соң, ниләр әйткән ул егет,— ди хан.

— Ниләр генә әйтмәгән, сөекле ханым. «Сез урдаларыгызны буйсындыра алмасагыз, мин буйсындырырмын» дип әйткән. Безнең иң гайрәтле сугышчыларыбызны «баскыннар» дип атаган,— ди Али бәй.

Хан, гаскәригә карап:

— Шулай дип әйттеме?

— Шулай, бөек ханым! — дип җавап бирә гаскәри.

Аннан соң да Али бәй сүзләрен дәвам итеп:

— Сөекле ханым! — ди.— Бу Чура, шулай сизенәм, безгә бер эш чыгарачак. Әгәр алдан ук чарасын күрмәсәк, атасы Нарык шикелле үк башыбызга бер бәла китермәгәе. Соңармыйк тагы, дим. Сүз уңае килгәндә шунысын да әйтим, ханым, бу чураның Тасмагер атлы бик яман яхшы йөгерек аты бар. Ул ат аңа түгел, сезгә лаек. Әмер итегез! Ун елдан артык берни бирмичә яшәгән өчен мин Нарык белән аның улы Чурага бер уен «уйнатаем»: аның Тасмагер атлы чаптарын алып сезгә киләем,— ди.

Боларны ишеткән хан, Али бәйгә карап:

— Алай булса, бар кит! Теләгәнеңне эшлә дә миңа шул Тасмагер дигән атны алып кил! — дип әмер бирә.

Иртәгәсе көнне Али бәй үзе белән кырык гаскәри алып, тузан уйнатып Нарыкның өенә килеп керә. Чура Батыр өйдә булмый. Ул каладагы дус-ишләрен күрер өчен бер җыенга киткән икән. Али бәй, камчысын чыгарып, ачуын китерер өчен Нарык картның башына, күзләренә суга. «Кырыгыбызга кырык кысыр бия табачаксың, кырыгыбызга кырык төрле ризык әзерләрсең»,— дип җикерә. Нарыктан симез-симез куйларын суйдыра, Чураның анасы Миңлесылуга күңелдән китмәс яман-яман сүзләр әйтә, казан-казан аш пешертеп, шулпа салдыра. Кыз кардәше Канибәкне каршысына чакырып, савытына баллы буза (исерткеч эчемлек) койдырта. Аннан соң, атларны китертеп, араларыннан Тасмагерны сайлап ала да, атына атланып, камчы белән Нарыкның башына-күзенә орып, акыра-бакыра чыгып китә.

Ул китә торсын. Башы-күзе канга баткан Нарык карт бер атка атланып җыен булган урынга бара, Чураны эзли. Ләкин эзләп-эзләп тә улы Чураны таба алмагач, «Бәлки минем тавышымны ишетер» дип, көй әйтә башлый:

Чурам Чура булганда,
Йөгерек атка менгәндә,
Акташлының Али бәе,
Йөзе кара, миңле бәй,
Яу күргәндә тиле бәй,
Чигәләре чиләктәй,
Аткан угы беләктәй,
Ат биленә менгән бәй.
Ат биленә менгәч тә
Баскынлыкка чыккан бәй.
Баскынлыкка чыккач та,
Илнең чите Нарык дип,
Карт Нарыкка килгән бәй.
Чурам Чура булганда,
Йөгерек атка менгәндә,
Акташлының Али бәе
Дус телендә килмәде,
Кунак телендә килмәде,
Безгә саулык теләмәде,
Камчы уйнатып торды,
Карт Нарыкның башы-күзе
Кара янсын дип торды.
Абзардагы куйларымнан
Симезләрен суйдыртты.
Картаеп беткән анаңа
Казан-казан ит астырып,
Кырык төрле ризык пешертеп,
Казанлап шулпа китертте.
Кыз кардәшең Канибәккә
Бармакларын тоттырып,
Баллы буза сөздертте.
Кырык ризыкны җыймады,

Баллы бузаны эчмәде,
Ат өстеннән төшмәде.
Алты аргамак бирдем, алмады,
Җиде йөгерек бирдем, алмады,
Җилҗитмәсне китереп бирдем, алмады,
Кошҗитмәсне тотып бирдем, алмады,
Тоягыбагарны китердем, алмады.
Дүрт тоягы дагалы,
Маңгае айдай тамгалы,
Койрыгы, ялы кыналы
Турыны бирдем, алмады.
Йөгергәндә тау бозган,
Чабышканда яу узган,
Һөнәрендә җылкыга биргесез,
Колагына камыш бәйләп җиткесез,
Тоягына чуен юллар тоткысыз,
Аяклары кайтандай[1]
Йөгергәне шайтандай,
Тасмагер атлы атыңны
Тартып алып китте бәй.
Картлыгым каршыма килгәндә,
Яшьлегем башымнан киткәндә,
Камчысын чал башыма тартты бәй.
Хәләл сөтен имгән анаңа
Күңелдән китмәс сүзләр әйтте, бәй.
Кыз кардәшең Канибәккә
Тимердән суык сүзләр катты, бәй.
Бу хурлыкны күргәндә,
Кайнар казандай ике күзем кайнады.
Акташлының Али дигән бәйләре
Аягының астына безне салып таптады.
Телдән әйтелмәслек сүзләр белән
Җаныбызны, рухыбызны таплады.
Чурам Чура булганда,
Йөгерек атка менгәндә,
Садагыңа булат кылыч салмасаң,
Чырылдатып кан үчемне алмасаң,
Арыслан улы Бәйгази,
Аның улы Ир-Түләк,
Аның улы Нарыктан
Син ул түгел, кыз тудың.

Бу сүзләрне ишетүгә Чура тиз генә атасы янына килеп, ачуланып мондый җыр әйтә:

---

[1]Кайтан — ефәк.

Чураң Чура булганда,
Йөгерек атка менгәндә,
Карт атама, Нарыкка
Килмәс хурлык китердем.
Тиз-тиз өйгә китәем,
Җилҗитмәскә менәем,
Коралларым тагаем,
Билем тартып бәйләем,
Ак кылычым алаем,
Уң билемә тагаем,
Ак күрәүкәм[1] алаем,
Ияремне салаем,
Акташлының Али бәен
Тизрәк куып җитәем,
Башын чабып өзәем,
Турам-турам итәем,
Калҗа-калҗа итәем.
Бүрткән куйдай кыркаем,
Бүредәй тотып ертаем,
Туралган иттәй тураем,
Ачуың аннан сораем.
Әйткәнемне итмәсәм,
Морадыма җитмәсәм,
Нарык улы мин Чура
Анамнан әрәм туган булаем.
Боларны әйтә-әйтә Чура батыр
Яман кызды, кызарды,
Бер агарды, бүзарды,
Ачуына чыдый алмый,
Боздай тимер кызарды.
Җилҗитмәсне ияртте,
Кошҗитмәскә менеп китте,
Шул китүдән китте-китте,
Үгез Түбәгә барып җитте.
Киблы байның йортында
Али бәйгә барып җитте.

Чура Батырның тиз куып җитеп, ихата капкасына килгәнен күреп, Али бәй аны капка алдына чыгып каршылый. Чура Батыр атларын туктатып, Кошҗитмәснең өстеннән төшмичә, башта Али бәйгә болай дип әйтә:

Әссәламәгаләйкем, Али бәй,
Яуларына меңле бәй,
Тасмагер атымның башына

---

[1] Күрәүкә — кымыз савыты.

Ничек сыйды нуктагыз?
Акташлының Али бәе,
Ат биленә менгән бәе
Минем атам Нарыкның
Йорт эченә кермәгән,
Бал-бузасын эчмәгән.
Кырык казан астырып,
Кырык ризык пешерткән,
Пешерткән дә җиймәгән.
Әй, бәй улы, Али бәй,
Җилҗитмәсне бирәем,
Кошҗитмәсне бирәем,
Кара көндә янында
Җан сакчысы булаем,
Сиңа саулык тели-тели
Яу алдында үләем.
Яхшылык белән әйтәмен,
Гафу сорап әйтәмен,
Бер Тасмагерны кайтарчы,
Ялварып сиңа әйтәмен.
Әйткән сүземә килсәнә,
Тасмагерны бирсәнә!

Чура Батырның яхшылык белән ялваруын күреп, Али бәй үз-үзенә «Куркыттым моны!» дип, тәкәбберләнеп болай ди:

Мин менермен, менермен,
Үч күтәрмәс ирдермен.
Кан ташыган бу көндә
Карагерың бирмим мин.
Сабыр ит, Чурам, сабыр ит,
Атыңның башын тартып кит,
Синең өчен түгел, онытма.
Буш башыңнан каршымда торып,
«Тасмагерны алырмын» дип,
Һич тә көтмә, кит, авызыңны корытма!

Мондый тискәре сүзләрне ишеткән Чура Батыр кызып китә һәм Али бәйгә болай ди:

Әй, Акташлы Али бәй,
Кара йөзле, миңле бәй,
Кое күргәндә ташкан бәй,
Яу күргәндә качкан бәй,
Мактанып күккә баккан бәй,
Кашың-күзең тонган бәй,
Халыкны елатып уңган бәй,
Моны ничек әйтерсең?

Акташлыңнан атланып,
Минем атай Нарык картка
Кунаклыкка баргансың,
Минем атам Нарык картның,
Камчыңны болгый-болгый,
Баш-күзенә чалгансың,
Моны ничек әйтерсең?
Казан-казан ит астырып,
Анам минем Миңсылуга
Күкрәктән китмәс сүзләр әйткәнсең,
Аны ничек итәрсең?
Баллы буза сөздертеп,
Кыз кардәшем Канибәккә
Тимердән суык сүзләр әйткәнсең,
Моны да ничек итәрсең?
Алты аргамак биргән, алмагансың,
Җиде йөгерек биргән, алмагансың,
Җилҗитмәсне биргән, алмагансың,
Кошҗитмәсне биргән, алмагансың,
Тоягыбагарны биргән, алмагансың,
Атылып барып җылкы эченә кергәнсең,
Тасмагерымны тотып алып,
Өстенә сикереп менгәнсең.
Көфер сүзләр әйтеп-әйтеп
Анам, атам, кардәшемә,
Юлыңа чыгып киткәнсең.
Әй, бәй улы, мин синнән
Бер сорыймын, бирмисең,
Ике сорыймын, бирмисең,
Күп сорыймын, бирмисең.
Бал кортларын үтерми,
Балын ничек алырсың?
Атымның башын тартмаячакмын, Али бәй!
Мин бу җирдән сугышмый кайтмаячакмын,
Али бәй!

Шуннан соң Али бәй Чура Батырга болай ди:

Көшерле тауга чык, Чура,
Синең күркең күрием,
Күк күлмәгең ки, Чура,
Һөнәреңне белием.
Көшерле таудан атылма,
Али бәйгә кагылма.
Көшерле таудан атылсаң,
Али бәйгә кагылсаң,
Үлгәндә яман үләрсең,

Кара җирнең астына
Бер йоклаусыз керерсең.

Чура Батырның Али бәйгә биргән җавабы:

Ай, бәй улы, Али бәй,
Ташыган судан тиле бәй,
Каф тавыдай нәфесең
Ил эченә сыймый, бәй.
Гаскәрем минем чиксез дип,
Күп мактанма, Али бәй.
Гаскәрең, әйдә, күп булсын,
Сан җитмәстәй күп булсын,
Гаскәреңнән күчәрсең,
Тасмагерымнан төшәрсең.
Тасмагерымны алырмын,
Синдәй шашкан бәйләрне
Ыргагым белән тартырмын,
Кылычым белән турармын.

Шуннан соң Али бәй белән Чура Батыр Көшерле тауга баралар. «Атышыйкмы, тотышыйкмы?» — дип сораганнан соң, Али бәй: «Атышыйк!» — ди.

Яшь сорады Али бәйдән:

— Атышыйк ни җай белән?
Яше өлкән бәй булды.
Бәйнең тартып аткан угы
Чураның ияр кашына кадалды.
Нарык улы Чура атты,
Али бәйнең йөрәгенә кадалды.
Хөсеткә баткан Али бәй,
Бер үгездәй үкереп,
Ияренә егылды.

Шулай итеп, Чура Батыр ыргагы белән Али бәйне ат өстеннән тартып-тартып төшерә дә, кылычы белән гәүдәсен кырыкка турап, башын чабып ала. Янындагы кырык саклавын[1] да куйдай кыркып, Тасмагерына атланып, Кошҗитмәс белән Җилҗитмәсне ияртеп, Көкешле Тамга каласына кайтып китә. Озакламый, тузан туздырып улының кайтып килгәнен күргән Нарык шундый җыру әйтә:

Анау кара күренгән
Каракош кара түгелме?
Хан саклавын үтергән
Куркусыз Чура түгелме?
Куркусызны мактап җибәрдек
Бу язмышның каршына,

[1]Саклау — хан яисә түрәләрне саклау өчен билгеләнгән гаскәр.

Кара үтергән каралмас,
Түрә үтергән котылмас,
Инде дә хәзер улым Чура
Бу Кырымның әчләрендә
Кайда качса да котылмас.

Әйтеп бетерер-бетермәс Чура Батыр кайтып та килә, атасына болай сөйли:

Ал, ал, атам, ал, атам,
Атларның башын тот, атам.
Али бәй бүген үлгәндә,
Синең йөзең көлгәндә,
Башын чабып какканда,
Ыргагыма такканда,
Атларымны әйди-әйди,
Куанып өйгә кайтканда,
Тау сыртларын кичкәндә,
Саба җиле искәндә
Яшьлегемне искә төшердем:
Чүлдә курай өргәнем,
Ашыт уйнап йөргәнем,
Бүз ат, бозау бакканым,
Чирәмлектә ятканым,
Кичен кояш батканда,
Йолдызлар җәйрәп ятканда
Балалар такмак әйткәнен,
Сызылып таңнар атканын,
Куанып өйгә кайтканым
Мәңге чыкмас исемнән.
Уйга батып кайтамын,
Сезне моңайтып әйтәмен,
Бу килүем соңгы килү,
Китсәм мин кайталмамын.
Кара үтергән каралмый,
Түрә үтергән котылмый,
Атам, сиңа әйтәмен,
Чураң Кырымда калалмый.

Чура Батыр, Кырымда рәхәт яши алмаячагын аңлап, «Кайда китим икән, кайда барыйм икән?» дип уйланып тора-тора да арыганлыктан йокыга тала. Бер төш күрә. Төшендә Казанга барган, имеш. Йокысыннан уянгач, Чура Кырымнан качып Казанга китмәкче була. Шул уен атасы Нарыкка әйтеп, рөхсәт сорап, болай дип әйтә:

Ал, ал, атам, ал, атам,
Саулыклар белән кал, атам.
Акташлының Али бәен үтердем,
Башыма бетмәс хурлык китердем.
Казан дигән ил бар дип,

Башым куяр җир бар дип,
Казналы Кырымны калдырып,
Мин Казанга барамын,
Халкына ярдәмче буламын.
Мин Казанга барганчы
Кан яумасын, кар яусын.
Мин Казанга баргачтын
Кар яумасын, кан яусын.
Мин Казанга барамын,
Казанны казак алмасын,
Талап юлга салмасын,
Тактасын утка якмасын,
Ташларын суга атмасын.
Алтмышка җиткән картларын
Туп алдына салмасын.
Көн күрмәгән яшь кызлары
Казакка килен булмасын.
Мин Казанга барамын,
Казан батыры буламын.

Атасы, Чураның китүенә ризалык биреп, аңа җавабында мондый сүзләр әйтә:

Бар, кит, улым, кит, улым,
Барганда бәхтең ачылсын,
Казан иленең капкасы
Кояшлы яктан ачылсын.
Тугыз ай, ун көн күтәргән,
Ун ай, ун көн имезгән,
Сиртмәле бишеккә таянган,
Иртә таңнан уянган,
Таң йокысын дүрт бүлгән,
Сине бәгыренә бастырып
Хәләл сөтен имезгән
Миңлесылу ананнан
Ризалык алып кит, улым!

Моны ишеткән анасы өйдән йөгереп чыга да, җибәрмәскә теләп, моңланып әйтә:

Китмәче, балам, китмәче,
Безне моңлы итмәче,
Картайганда атаңның
Билен яман бөкмәче,
Газиз анаң гарьләндереп
Күкрәкләрен измәче,
Канибәк дигән кыз кардәшең
Күз яшьләрен түкмәче!

Чура анасына әйтә:

Ал, ал, анам, ал, анам,

Ак саулык белән кал, анам!
Тугыз ай, ун көн күтәргән,
Ун ай, ун көн имезгән,
Сиртмәле бишеккә таянган,
Иртә таңнан уянган;
Таң йокыңны дүрт бүлеп,
Суырып сөтең имгәнмен,
Бәгыреңә бастырганда
Йөрәгеңә сеңгәнмен.
Бүгенге хәлемне күрсәнә,
Имгән сөтең хәләл итсәнә,
Мин китәем, газиз анам,
Ризалыгың бирсәнә!

Боларны ишетеп, анасы болай ди:

Бар, алайса, бар, балам,
Барганда бәхетең ачылсын!
Казан иленең капкасы
Кояшлы яктан ачылсын!
Кил, балам, сине сөяем,
Башың, күзең сыйпаем,
Ак юл теләп калаем.

Кыз кардәше Канибәк йөгереп өйдән чыга да агасының муенына сарыла, мондый сүзләр әйтеп, такмаклап елый:

Тасмагер атыңа менгәнсең,
Койрыгы белән ялларын
Ефәкләр белән үргәнсең,
Агам, кая китәсең?
Ук-җәяңне таккансың,
Ук алмаган калканыңны
Уң иңсәңә аскансың,
Агам, кая китәсең?
Укалы кием кигәнсең,
Ук-садагың элгәнсең,
Сул кулыңа кош тотып,
Агам, кая китәсең?
Картайганда ата-анамны
Елатып кая китәсең?
Канибәк сөйгән кардәшеңне
Кемгә әманәт итәсең?

Чура Батыр кыз кардәше Канибәккә каршы төшеп, мондый җавап бирә:

Тасмагерга менгәнмен,
Койрыгын, ялын үргәнмен,
Тузан кунмасын дигәнмен.

Угым-җәям такканмын,
Ук алмаган калканымны
Уң иңемә асканмын,
Яулар күреп качсын диеп,
Булат кылыч бәйләдем,
Кырымга керегә әйләндем.
Укалы кием киеп,
Сул кулыма кош тотып,
Казналы Кырымны калдырып,
Җитмеш чакрымлык[1] Казанга
Ярдәм итәргә барамын.
Мин Казанга барганчы
Кан яумасын, кар яусын,
Мин Казанга баргачтын
Кар яумасын, кан яусын.
Елама, кардәшем, елама,
Уйнап-көлеп китәем.
Мин Казанга җитәем,
Халкына ярдәм итәем.
Китсәм, шәһит китәем,
Үлем ширбәтен эчәем!

Шуннан соң, Чура инде китәргә җыенганда, атасы Нарык аңа шушындый нәсыйхәт бирә:

Бай тирәкнең чайкалуы җилдәндер,
Карт тирәкнең шарт сынуы билдәндер,
Тереләрнең көн итүе илдәндер,
Ак киекнең йөрер җире мәйдандыр.
Абдал булса, ат та яу,
Кытымыр булса, карт та яу,
Гомере булса, кортка яу,
Кылычы булса, ул да яу,
Йөрүчән булса, килен яу,
Уйнак булса, кыз да яу.
Томанлы көндә төлке узар,
Буранлы көндә бүре узар,
Җайлап чапса, ат узар,
Биш бизәнгән туйда узар,
Яхшы кеше көн дә узар.
Кодалак арба[2] юл бозар,
Яман бикә өй бозар.
«Көчем бар!» дип мактанма,
Көчең китәр көн булыр;

[1] Ерак дигәнне белдерә.
[2] Кодалак арба — ике тәгәрмәчле арба.

«Малым бар!» дип мактанма,
Малың бетәр көн булыр;
«Туганмын!» дип куанма,
Туган, үлгән көн булыр;
Җаның чыгар көнеңнән
Котылмастай көн булыр;
Бер үзеңнән башкасын
Күңелгә алмас көн булыр;
Күргән җирдә күз калыр,
Йөргән җирдә эз калыр.
Кардәш үлсә, кан калыр,
Сердәш үлсә, сер калыр,
Уйнаш үлсә, тол калыр,
Кемне сөйсә, шуны алыр.
Егет үлсә, исме калыр,
Аты үлсә, ияре калыр;
Җиңгән үлсә, малы калыр,
Мал артыннан күз калыр;
Калганнарга гаугага
Алтын, көмеш, таш калыр;
Әҗәл җитми үлем юк,
Үлем вакытын белү юк;
Әҗәл җитеп үлгәннән соң,
Һич бераүгә калмак юк.
Бу дөньяга килгәчтен,
Үлми калган бераү юк.
Әҗәл җитсә, әмәл юк,
Котылмага гамәл юк,
Еласаң да файда юк.
Хатын калса, ир табар,
Кызың калса, яр табар,
Улың калса, мал табар.
Менгән атың буш калса,
Менәргә ир табылыр,
Кигән туның буш калса,
Кияргә ир табылыр.
Киткәндә ни табылыр?
Әйткәннәремнән чыкма син,
Кич җиткәндә атка атланып,
Ярганак таудан кичмә син.
Казандагы Гәрәй ханның
Сарае алдыннан үтмә син.
Сусаганда яр буендагы
Суларыннан эчмә син,
Казандагы картларның
Теләген кире какма син.

Берәүнең кылыгын күрдем дип,
Еландай барып чакма син.
Казанга барып җиткәчтен,
Җир табалмый йөресәң,
Сәли картны кара син.
«Синең улың буламын!» дип,
Сәламемне әйт аңа син!
Сәли карт сиңа юл табар,
Юл тапмаса, җир табар,
Җирлеләрдән ир табар,
Дуслашып ул синең белән
Кайда кирәк, ат чабар.
Китсәң, улым, атлан, кит!
Аш ашамый, су эчми,
Кичә-көндез йокламый,
Сине сагынып саргайган
Алтын-кызны күреп кит!

Чура батыр, атасының әйткәннәрен тыңлап, ата-анасы, кыз кардәшенең хәер-фатихасын алып, аларга саулык теләп, болай ди:

Исән-сау кал, атаем,
Әйткәннәреңнең һәммәсен
Колагыма киртләем!
Сәли картны табып мин
Сәламеңне әйтермен.
Мин Казанга барсам да
Хан булырга бармыймын,
Бәй булырга бармыймын.
Хан итсәләр, булмамын,
Бәй итсәләр, калмамын.
Исән-сау кал, анаем!
Исән-сау кал, кардәшем!
Мин Казанга баргачтын,
Йолдызлар булыр юлдашым.

Чура Батыр атына атланып, сөйгән кызы Алтыннан да хәер-фатиха алу өчен юлга чыга. Ерактан ук аның килгәнен күреп, Алтын бик куана, Чураны мондый такмак белән каршы ала:

Анда камыш, монда камыш арасыннан
Томан чыга урап-урап.
Әнә миңа Чурачыгым килеп ята,
Ул бит миңа иң кадерле, газиз кунак.
Чурачыгым, ат бирәем, тун бирәем,
Ак атыңның иярен мин салдыраем,
Төлке туның үзем тотып кигезәем,

Гөлчәчәкләр арасына яткыраем.
Ун бармагымны шартлатып уйнатаем,
Син аруга нарлы[1] табын җыйнатаем.

Чура Батыр сөеклесе Алтынның җырын йөрәге ярылырдай хәлгә килеп тыңласа да, аңа барып болай ди:

Ал, ак Алтыным, аруым,
Ал, исән-сау кал, аруым.
Акташлының Али бәен мин үтердем,
Башыма бетмәс хурлык китердем.
Менәргә бирсәң, тулпар бир,
Чапкан саен арымас.
Кияргә бирсәң, көбә бир,
Тарткалашсам, ертылмас.
Сөям дисәң, вәгъдәңне бир,
Чураң сине онытмас.
Казан дигән ил бар дип,
Башым куяр җир бар дип,
Казналы Кырымны калдырып,
Син гүзәлне моңайтып,
Мин Казанга барамын,
Казанда батыр буламын.

Алтын моңа каршы Чурага җыр әйтә:

Ай ни булыр көннән соң?
Көн ни булыр айдан соң?
Ул ни була икән дип сорасаң:
Айның анасы диңгез булыр
Тынып торган күлдән соң.
Кара канат бөркетем
Ниләр тотып, ни ашар,
Иделдән күп чүпләгән
Казлар, кошлар беткәчтен.
....
Мактанып ла булмый икән,
Дәүләт баштан кичкәчтен.
Батырлык кылып булмый икән
Атың өркеп киткәчтен.
Манарасы күккә үрелгән күк сарай
Харап булып бетә икән
Түбәсенә яшен бәреп үткәчтен.
Янып торган гөлчәчәк
Курай булыр сулгачтын,

[1]Нарлы — татлы.

Елтырап торган кызыл ефәк
Челтәр булыр тузгачтын.
Картаеп киткән гүзәлләр
Кортка булыр узгачтын.
Икмәк ашамам нардан соң,
Казы ашамам кардан соң,
Кияүгә чыкмам синнән соң.
Көнләшеп торган бер яман,
Һаман-һаман күз атып,
Бик күп хурлык китерер
Син аруым киткәчтен.
Алып кит мине, Чурам, алып кит,
Атың ялына салып кит!
Артыңнан рәхимсез яу куганда
Алтын атлы аруыңны,
Ыргагың белән элеп алып,
Корбан итеп чалып кит!

Чура юлга чыгып барганда аңа иңнәренә су тутырган көянтә аскан, судан кайтып килүче бер киленчәк очрый. Чураның киенеп, коралларын асып китеп баруын күреп, киленчәк, аның кем икәнен белим дип, Чурага сүз катып, болай дип сорый:

Кара кашлым, җирән атка утырып,
Садагыңа яңа уклар тутырып,
Ук алмаган калканыңны
Уң иңсәңә астырып,
Биштәрләреңь тутырып,
Укалы киемнәр киенеп,
Сул кулыңа кош тотып,
Билеңә кылыч тагып,
Казналы Кырымны калдырып,
Яу каршысына баргандай
Икендедән ил ташлап,
Түрәм, кая барасың?
Чура Батыр киленчәккә җавап бирә:
Түрә түгел, карамын,
Игез түгел, ялгызмын.
Каламның исмен сорасаң,
Көкешле Тамга, диерләр,
Шуннан китеп барамын.
Үземнең исмем сорасаң,
Арыслан улы Бәйгази,
Аның улы Ир-Түләк,
Аның улы Ир-Нарык,
Чура улы Чурамын.
Барыр җирем сорасаң,
Җитмеш чакрымлык Казанга

Кара көндә җыенып,
Ярдәм итәргә барамын.
Мин Казанга барганчы
Казанны казак алмаса,
Таптап юлга салмаса,
Тактасын утка якмаса,
Ташларын суга атмаса,
Алтмышка җиткән картларын
Туп алдына салмаса,
Көн күрмәгән гүзәлләр
Яуга килен булмаса,
Сабый-сабый балалар
Елап үксез калмаса,
Кара киенгән Казанның
Каласының эчендә,
Капкасының төбендә
Ташка суккан
Тимершыгы[1] булырмын.

Шулай итеп, Чура Казанга барып җитә. Аны сарай кызларыннан берсе күреп, йөгереп ханбикә Сөембикә янына керә һәм болай дип әйтә:

Казанның саф урамын кичкәндә,
Сараеңның каршысына килгәндә,
Астындагы җирән аты сөрлекте,
Башындагы күн бүреген төшерде.
Кара кашы, кара чәче күренде,
Айдай йөзе, күз карашы ачылды,
Менә бу килгән мөсафир
Акташлының Али бәен үтергән,
Үзенә бетмәс хурлык китергән,
Хан илендә хәсрәтле
Чура Батырга бик охшаган.

Чура Батыр Казанга килгәч хан сараена тукталмый, атасының киңәше буенча каланың бер төбәгендә яшәп ятучы Сәли картны эзләп таба, аңа болай дип эндәшә:

Әй, Сәли карт, Сәли карт,
Сәлам бирдем сезләргә,
Сәлам бирдем Сәли атам,
Алмыйсыңмы өеңә?
Җаның аврып син мине
Ала калсаң өеңә,
Атам йорты Казанга
Кайчан кара көн туса,

[1]Тимершык — тимер калканы мәгънәсендә.

Мыегымны борырмын,
Мин яуларны куырмын.
Сәли карт Чурага карап болай ди:
Сиксән бишкә җиттем мин,
Сиксән батыр күрдем мин.
Туксан бишкә җиттем мин,
Туксан батыр күрдем мин.
Инде хәзер бу көндә
Туксан тугызны үтеп барам мин.
Кем икәнең белә алмый
Уйга калып торам мин.
Асылыңны әйтсәнә,
Нәселеңне әйтсәнә,
Кем икәнең белим мин,
Өемә алып керим мин.
Чура Сәли картка әйтә:
Мин ерактан, ерактан,
Бик ерактан килдем мин.
Асылымны сорасаң,
Кырымдагы Көкешле Тамганың
Куылган бер улымын.
Атамның атын сорасаң,
Арыслан улы Бәйгази,
Аның улы Ир-Түләк,
Аның улы Ир-Нарык
Чура улы Чурамын,
Аннан сәлам әйтәмен.
Бу көнемне сорасаң,
Кабан күлендә яшәгән,
Ил икмәген ашаган
Сәли карт, синең улыңмын.

Сәли карт Чурага җавап бирә:

Өйгә кер дип әйтергә,
Карт атаңның җае юк,
Җаен табып кайтыем,
Җаена салыр шае юк.
Бер улы юк, кызы юк,
Фәкыйрь, мескен агамын,
Күкрәкләрем шыгырдый,
Йөрергә бер җаем юк.
Өйгә кереп син, балам,
Карт анаңның кулын үп!

Шулай итеп, Чура Батыр Сәли картның улы булып, аңа ярдәм итеп яши башлый. Көннәрнең берендә Сәли карт Чураны Казан батырларының җыенына алып бара да такмак әйтә башлый:

Кемнәр юк та, кемнәр бар,
Бу җыенның эчендә.
Төрле-төрле байлар бар,
Төрләнмәгән батыр бар.
Кабан күлендә камыш бар,
Күл эчендә таныш бар,
Таныш эчендә Чура бар,
Ышанмасаң, кара, бар!
Моннан да өлкән кала бар.
Кабан күлендә колан[1] бар.
Күл эчендә елан бар,
Елан башлы дошман бар.
Илдән алым алдырмас[2]
Изге туган Мамай бар.
Капчыгы белән тугайда
Гомер кичкән Нугай бар.
Ханның Гамбәр улы бар,
Үзгә булсаң, аңа бар,
Бияләр менеп туй иткән,
Тауда Казый Мирза бар.
Җырчы булсаң, анда бар,
Сарайда Колынчак батыр бар,
Батыр булсаң, аңа бар.
Алынчак атлы дусты бар,
Аңа булсаң, аңа бар.
Кара сөңге кулга алган,
Капка авызына таянган
Чынаяк[3] сөяр иле бар,
Сәлинең улы Чура бар,
Ач капканың арасын,
Ышанмасаң, кара, бар!

Ләкин беркем дә Чурага игътибар итми. Чура үпкәләп, аларга карап болай ди:

Колынчак белән Алынчак,
Сарай эчендә яшәгәч,
Мактанырга әвәсләр.
Сәли картның өендә
Алты ай инде яшимен,
Табынына утырып,
Икмәк-тозын ашыймын.
Танымады берегез,
Халык әйткән хак икән,
Айсыз икән ханыгыз.

---

[1] К о л а н — кыргый ат.
[2] А л ы м а л д ы р м а с — илне талатмас.
[3] Ч ы н а я к — кытай савыты, фарфор; биредә затлы әйбер дигән мәгънәне дә белдерә.

Бу Казанның ханы бар да, намы юк.
Казые бар, түрә юк.
Күрәмен дә беләмен,
Баллы буза теләрмен.
Казанны басып яу килсә,
Нәтиҗәсен белермен.

Шуннан соң Колынчак Батыр аның янына килеп сорый:

Иртә таңнан, сәхәрдән,
Сөембикә сараеның
Каршысына килгәндә
Җирән аты сөрлеккән
Нарык улы синме идең?
Кабан күлендә яшәгән,
Алты ай мөсафир булып ашаган
Нарык улы синме идең?
Ук-садагың элмәгән,
Күренеп һич йөрмәгән,
Күренеп йөрми танышкан
Нарык улы синме инде?

Шуннан соң Колынчак Батыр, юлдашларына карап, аларга болай ди:

Аргамагына арпа биреп,
Тал-тирәккә бәйләгез,
Кулыгыз белән сыйпагыз.
Кара көндә, кыенда,
Татар атына юл биреп,
Танавыннан кан килеп,
Тырпаеп торса, күрерсез!
Казан арты бүз камыш,
Бүз камыш та нар камыш.
Бүгеннән башлап сез аны
Орышканда күрерсез.
Сырага килгән батырга
Тустаганын бирегез.
Казан атлы калага,
Чарылдап гаскәр килгәндә
Карап торса, күрерсез.
Чура Батыр аларга карап әйтә:
Кабыргама каткан каты иттә
Каным кайнап утырса,
Кан чыкмаган сөягемдә
Бөркет кош оялап утыра.
Газизләнгән бу җаным
Бу Казанның үзе өчен
Шәһит китәргә тора.

Шуннан соң Чура, Сәли картның өенә кайтып, анда яшәвен дәвам иттерә.

Ләкин Кырымда калган атасы Нарыкны хан җәзалап, мал-мөлкәтен алып, бер теләнче хәленә җиткергән. Нарык карт теләнә-теләнә йөреп Казанга килеп чыга һәм болай дип җырлый:

Казна-казна мал килсә,
Казначылар куаныр.
Кала төбенә яу килсә,
Колынчак белән Ир-Чура
Кара канга буялыр.
Шундый батыр Чура атасы,
Инде килеп бу көндә,
Кыршаулы чиләк кулга алып,
Илдән-илгә йөридер.

Чура, атасын каршы алып, кулыннан килгәнчә мал биреп, разый итеп, озатып җибәрә. Шуннан соң Казан өстенә яу килә. Ул көннәрдә Чура Батыр егетләрчә сугышып, яуны кире кайтара. Шулай итеп, Чура Батыр дан казанып, тугыз ел, тугыз ай Казанга һичбер яу күрсәтми, һәммәсен дә кире кагып бара. Әмма сәфәр аенда бик канлы сугыш була. Яулар Казанны сарып алалар. Җир астыннан юл казып, Казан каласының астына дары салып, каланы һавага очыралар. Бу вәхшәт эчендә халык аһ-зар булып, капмакарышып, кайда качып котылырга белми. Һәр җир кан эчендә, туздырылган, тар-мар ителгән. Батырларның бер өлеше шәһит киткән, бер өлеше әсир төшкән була. Чура Батыр ялгыз калып, манара җимерекләре өстендә яулар белән кылычка-кылыч килә, бермәлдән күрә: дүрт ягыннан дошман гаскәре белән чорнап алынган. Качып котылыр юлы бер генә — Иделнең текә яры. «Яу кулына әсир төшеп хур булганчы, үземне ярдан атаем!» — ди дә, Тасмагер аты белән үзен кыядан Иделгә атып, анда аты белән икесе дә батып үләләр.

Көннәрдән бер көнне Казанга улын эзләп Чураның анасы килеп чыга. Ул җимерелгән, яндырылган Казан урамнары буйлап йөри, очраган һәр кешедән Чураны сорый. Әмма Казанда һәр кешенең үз кайгысы. Миңлесылуны искә алып, аңа колак салучы кемсә юк. Иң соңында ул болай дип әйтә:

Ата дөя акырып,
Бүз таналар бакырып,
Ыңраша торган бер көндә,
Чурам менгән Тасмагер,
Ачуланып, көрсенеп
Кара суга баткан көндә,
Айдай парлак Чурамны
Күргән бармы, бикәләр?

Моны ишеткән бер кыз аңа әйтә:

Ай, ай, кортка, ай, кортка,
Капчык асып муйныңа
Син дә нигә килгәнсең
Бу кыенлы Казанга?

Тере булып йөрсәң дә,
Син, әй, инде үлгәнсең.
Коллык, тарлык килгәндә
Син дә кемгә кирәксең?

Миңлесылу сүзен дәвам иттерә:

Карчыгадан туган тургайдай,
Ханнан туган солтандай,
Әй, бикәләр, тутайлар,
Кайсыгыз ул тапкансыз,
Казан каласын казанган
Кан яралы Чурадай?
Бармактагы уймагым,
Ак көмештәй тырнагым.
Икесе бергә килгән
Бу хурлыкка түзә алмый,
Баласы үлгән дөядәй,
Үкси-үкси киләмен.
Җан бәгърем Чурамның
Бүген үлгәнен белдем мин.
Бу Казанның картыннан,
Ятим калган яшеннән
Сораганнан файда юк!
Мәгарәгә барыем,
Әбелкасыйм хәзрәттән
Улымны барып сорыем.
Әбелкасыйм хәзрәт
Миңа карап көрсенә.
— Йөрәк парәм Чурамның
Каберен генә әйтсәнә!

Әбелкасыйм хәзрәт аңа болай дип әйтә:

— Ай, ай, анам, ай, анам,
Ай егылган күренә,
Көн егылган күренә.
Ай белән кояш кушылып
Күлгә төшкән күренә,
Миңлесылу анайның
Күзе чыкканы күренә.
Һәммәсен дә әйтимме?
Синең улың Ир-Чура
Тугыз ел да тугыз ай
Бу Казанда сугышып,
Батырлыгын нам итеп,
Ахырында, ай, мәдәт,
Суга баткан күренә.

Моны ишеткәч, Чура Батырның анасы Миңлесылу болай дип елый:

Ай, ай, көнем, ай, көнем,
Җаным, бәгърем, Чура улым,
Суга баткан бер улым.
Кайгылар, сөенечләрең
Истән китмәс үк булдың.
Юк булдың, Чурам, юк булдың,
Инде нәрсә итәем?
Баласы үлгән дөядәй
Бызлый-бызлый китәем.
Хикәятем бетте-китте,
Өйдә чыра сүнде-китте.

ТАҢБАТЫР

Борын-борын заманда булган икән, ди, бер патша. Бу патшаның булган, ди, өч кызы. Патша кызлары берсеннән-берсе матур булганнар, ди. Көннәрдән бер көнне бу өч кыз болынлыкка йөрергә дип чыкканнар. Болар болынлыкта йөргән вакытта гына бик каты җил-давыл чыга да кызларның өчесен дә күтәреп алып та китә. Патша үзенең кызларының югалганын белеп, бик зур кайгыга төшә. Көн эзләтә патша бу кызларны, төн эзләтә, үз патшалыгында урманы, су буйлары калмый моның, бөтен җирдән эзләтеп карыйлар, кызларны таба алмыйлар.

Шул патша торган шәһәрнең читендәге кечкенә генә бер йортта яшәгәннәр икән, ди, бер ир белән бер хатын. Болар бик фәкыйрь булганнар. Боларның булган икән, ди, өч уллары. Олы улларын Кичбатыр дип, уртанчысын Төнбатыр дип, ә иң кечесен Таңбатыр дип йөрткәннәр, ди. Бу егетләр, ай үсәсен көн үсеп, ел үсәсен ай үсеп дигәндәй, бик тиз вакыт эчендә дәү булып җиткәннәр, ди.

Үсеп җиту белән болар урамга уйнарга чыгалар. Яшьләр арасында болардан да көчле берәү дә булмый. Уйнаган вакытларында кешенең кай җиреннән генә тотсалар да умыралар да алалар, ди, болар. Кәшәкә шаралый[1] уйнаганда болардан да оста уйнаучы юк, көрәшә башласалар да, кешене имгәтми калдырмыйлар, ди, болар.

Бу өч туганның көчләрен кая куярга белми йөргәннәрен күреп, бер карт кына кеше әйткән, ди, боларга:

— Сез, ди, анда-монда сугылып, урынсызга кеше имгәтеп йөргәнче, әнә патша кызларын табып алып кайтып бирер идегез, менә шунда күренер иде сезнең батырлыгыгыз.

Шуннан соң болар, өйләренә кайтып, ата-аналарыннан рөхсәт сорыйлар:

— Әти, патша кызлары югалган, дип әйтәләр, без шул кызларны алып кайтып бирик микән әллә?

Ата-аналарының боларны бер дә җибәрәселәре килми, ризалык бирмиләр икән, ди.

— Әй, улларым, без сезне теләп кенә алдык бит инде, сез чыгып киткәч, безне кем карар, кем туйдырыр? — ди этиләре.

Малайлары әйтә:

— Әй, эти, без патша эше белән йөргәч, сезне патша тәрбияләр әле,— диләр.

— Юк инде, безгә патшадан бер рәхим дә, бернинди ярдәм дә буласы юк,— дип, этиәниләре елашалар.

---

[1] Кәшәкә шаралый — шарлы кәшәкә (туплы хоккей).

Бу өч батыр әти-әниләреннән бик инәлеп сорыйлар да, рөхсәт алып, патшага барып әйтәләр:

— Менә без синең кызларыңны эзләргә чыгарга уйлыйбыз, безнең үзебез белән алып чыгарга бернәрсәбез дә юк; әти-әниләр дә бик фәкыйрь торалар,— диләр.

Патша боларга ашарга-эчәргә бераз азык бирергә була.

Әти-әниләре белән саубуллашып, өч егет чыгып китә юлга. Баралар-баралар болар, атна китәләр, ай китәләр, бара торгач, барып керәләр бер урманга. Урманның эченәрәк керә барган саен, болар бара торган юл тарайганнан-тарая барып, соңыннан тар гына бер сукмакка калган, ди. Шул тар сукмак белән бара торгач, болар килеп чыккан, ди, бик матур бер күл янына. Ул вакытта инде ашарларына беткән була. Таңбатыр әнисе «юлда кирәк булыр» дип биреп җибәргән энәсен ала да, ут ягып, шул энәне утта кыздырып, бик шәп бер кармак ясый. Шуннан соң, су буена төшеп, балык тота башлый. Кичкә хәтле бер-ике пот балык тота да бу, шул балыкларын пешереп, абыйларын туйганчы ашата. Хәзер тамак кайгысы бетте инде боларның. Таңбатыр әйтә абыйларына:

— Безнең өйдән чыгып киткәнгә бик күп вакыт үтте, ди, без кай җирләрдә йөргәнебезне дә белмибез, бернәрсә дә күргәнебез юк әле безнең,— ди.

Абыйлары бер җавап та бирмәгән моңа. Шуннан соң бу, бик биек бер агач башына менеп, тирә-якны карый башлый. Таңбатырның агач башына менеп утыруы гына була, кузгала җил-давыл, кузгала җил-давыл, бу давыл шулхәтле көчле була, юлына туры килгән калын-калын агачларның башларын кыеп кына алып китә икән, ди. Таңбатыр җил-давылның котырганын карап тора да: «Әллә бу патша кызларын күтәреп алып киткән җил-давыл микән?» — дип уйлый. Озак та үтми, әлеге җил-давыл бер җирдә бөтерелеп котчыккыч булып өерелеп-өерелеп тора да бер биек тау башына барып туктый. Тау башында бик яман бөтерелеп тора-тора да бик ямьсез бер нәрсәгә — дию пәриенә әверелә. Дию пәриенә әверелә дә бу, тау кырыена төшеп, шундагы бер зур тишеккә кереп китә.

Таңбатыр, тиз генә агач башыннан төшеп, дию кергән тишекне эзләп таба. Бик зур тишек икән, ди, бу. Шуннан соң Таңбатыр, зур гына бер таш алып килеп, әлеге тишекнең авызын томалап куя да тиз генә барып абыйларын уята. Абыйлары бер дә ашыкмый торган кешеләр була. Әкрен генә торып, Таңбатыр хәзерләп куйган балыкны пешереп, туйганчы ашап-эчкәннән соң гына теге тау тишеге янына китәләр.

— Менә ул шушы тишеккә кереп югалды, без аның артыннан төшәргә уйласак, башта менә шушы ташны алып ташлыйк,— ди Таңбатыр.

Кичбатыр ташка барып тотына — кузгата алмый. Төнбатыр барып тотына — аннан да бернәрсә дә чыкмый. Шуннан соң Таңбатыр ташны күтәреп алып селтәп кенә җибәрә — таш тау астына тәгәрәп төшеп китә. Таңбатыр әйтә абыйларына:

— Безнең беребезгә менә шушы тишектән төшеп теге диюне эзләп табарга кирәк, ди, патша кызларын шул урламадымы икән? — ди.

Өч ир туган бергәләп киңәшәләр дә, урманга кереп, кочак-кочак юкә суеп алып чыгалар. Шул юкәләрдән бик калын итеп аркан ишә башлыйлар. Өч көн, өч төн буена бик нык, бик озын итеп ишәләр болар арканны. Шул арканның бер очын Кичбатырның биленә бәйләп, аны тау тишегенә төшереп җибәрәләр. Төшеп китә бу. Кич булды дигәндә генә арканны селкетә Кичбатыр: «Тартып чыгарыгыз»,— дип. Энеләре тартып чыгаралар.

— Төбенә җитә алмадым, аркан кыска булды,— ди Кичбатыр.

Шуннан соң болар тагын бер тәүлек аркан ишәләр. Хәзер инде шул арканга бәйләп

Төнбатырны төшереп җибәрәләр. Көтәләр-көтәләр болар, тегеннән бер хәбәр дә юк. Бер көн, бер төн үтте дигәндә арканны селкетә теге. Моны да тартып чыгаралар.

— Бик тирән икән, төбенә җитеп булмады, аркан җитмәде,— ди Төнбатыр.

Шуннан соң болар тагын ике төн, ике көн буена утырып аркан ишәләр. Арканны тагын да озын итеп ишеп, аның бер очын Таңбатырның биленә бәйлиләр. Тау тишегенә төшәр алдыннан Таңбатыр әйтә абыйларына:

— Тиз генә чыга алмасам, сез мине нәкъ бер ел көтегез, ди. Бер ел тулды дигәндә чыгып җитмәсәм, көтеп тормагыз, үз юлыгызны карагыз,— ди.

Шулай ди дә Таңбатыр, абыйлары белән саубуллашып, тау тишегенә төшеп китә.

Ярар, Таңбатырның абыйлары шунда калып торсыннар. Без хәзер Таңбатыр белән аска төшик.

Төшә-төшә Таңбатыр, нихәтле вакыт төшеп тә, тау тишегенең төбенә җитә алмый, арканы тагын да кыска була моның. Кире чыгасы килмичә, кылычын алып, арканны кисеп җибәрә бу. Бик озак очканнан соң, барып бәрелә бу бик каты нәрсәгә. Шунда ук һушыннан китеп, өч тәүлек аңына килә алмыйча ята, ди, бу. Шуннан соң, әкрен генә торып, тагын да китә бу. Бара-бара бу, шулай итеп бара торгач, моңа бер тычкан очрый. Бу тычкан бер генә мәртәбә селкенә дә кеше була.

— Нихәл, Таңбатыр, нишләп йөрисең монда? — ди.

— Менә,— ди егет,— бер дию пәриен эзләп төшкән идем дә, монда китәргә урын юк, чыгарга җай юк,— ди.

Тычкан әйтә:

— Ул дию пәрие сезне алдады бит, ди, сезнең элекке арканыгыз да тау тишеге төбенә җиткән иде, дию, сезне алдап, чокырның төбен аскарак төшереп җибәрде, ди. Хәзер син бик тирәндә инде, мин булышмыйча моннан чыга алмассың,— ди.

Егет нәрсә эшләргә дә белмичә аптырап торганда, тычкан әйтә:

— Менә мин сиңа дүрт полк тычкан солдаты бирим, ди, алар җирне казып торырлар, ә син таптап менеп кенә торырсың, ди. Шулай итеп, алар сине менгереп җиткерерләр бер сукмакка хәтле, ди. Шул сукмак белән җиде көн, җиде төн буена, бернәрсә күрмичә, караңгыда барырга туры килер, курыкма, ди. Шул юл белән бара торгач, сиңа очрар җиде кат чуен капка, ди, шул капкаларны ватып чыга алсаң, якты дөньяга чыгарсың, вата алмасаң, сиңа бик авырга килер, ди. Якты дөньяга чыгу белән янә бер сукмак булыр, син шул сукмак белән китәрсең. Шул сукмак белән җиде тәүлек барганнан соң күренер сиңа бер сарай,— ди.

Шулай ди дә бу, яңадан бер генә мәртәбә селкенү белән тычкан сурәтенә кереп, күздән югала.

Егет, дүрт полк тычкан солдатлары казыган юл белән бик күп вакытлар барганнан соң, барып җитә теге җиде чуен капка янына. Барып җитү белән, үзенең чукмарын алып, капкага бик каты итеп сугып җибәрә, чуен капка таралып китә. Шулай итеп, бу җиде капканы да бәреп үтеп китә. Бара-бара бу, барган саен дөнья яктырганнан-яктыра бара, ди. Җиде тәүлек юл киткәч, моңа зур кирпечкә охшаган бер кызыл нәрсә күренә. Барып җитә бу, янына барып карый: зур бер кирпеч икән . Кирпеч өстендә бакыр атка атланган, бакырдан коелган киемнәр кигән бер каравылчы тора икән, ди.

— Әй, адәм заты,— ди каравылчы,— бу тирәдән кит җәтрәк. Син бу тирәгә ялгышып кына килеп кергәнсеңдер, дию патша кайтып керсә, тотып ашар үзеңне,— ди.

Егет әйтә:

— Әллә ул ашар, әллә мин аның башына җитәрмен, анысын белеп булмый әле, ди. Хәзергә минем бик каты ашыйсым килә, китер әле берәр нәрсә ашарга,— ди.

— Сиңа ашатырлык бернәрсәм дә юк шул, ди, минә хуҗам кайткач ашатырмын дип хәзерләп куйган бер түшкә үгез ите, бер мич ипием, бер мичкә әче суым бар, шуннан башка бернәрсәм дә юк,— ди.

Егет әйтә:

— Ярар, ди, хәзергә миңа шулар да җитеп торыр, ә хуҗаңа ашап-эчеп торырга туры да килмәс,— ди.

Шуннан соң теге кеше, атыннан төшеп, бакыр киемен сала да Таңбатырга ашарга хәзерләп бирә. Бу — солдат киеме кигән кыз кеше икән. Егет әлеге кыз китергәннәрнең барын да ашап бетереп йокларга ятарга җыена. Ятар алдыннан сораша инде кыздан:

— Ул дию пәрие кайчан кайтыр икән? — ди.

— Ул иртәгә иртә белән менә шушы бакыр күпер өстеннән кайтыр,— ди кыз.

Егет әйтә:

— Менә сиңа бер без, ди, дию кайта башлагач, шушы без белән минем чигәмә чәнчеп уятырсың,— ди.

Шулай ди дә йокларга ята бу.

Диюнең кайтыр вакыты җитү белән теге кыз моны уятырга тотына, уята алмый. Без белән чәнчергә кызгана, уятмый калдырсам да яхшы түгел, дип уйлый. Шулай да бик каты итеп уята башлагач, Таңбатыр сикереп тора:

— Әй, ди, мине без белән чәнчеп уятырга кирәк иде, ул вакытта мин тагын да зәһәрләнебрәк китәр идем,— ди.

Таңбатыр теге кыз әйткән бакыр күпер астына кереп ята. Бервакытны, җил-давыл куптарып, дию бакыр күпергә якынлаша башлый. Күпер янына иң элек моның эте килеп җитә. Диюнең эте күпер янына килеп җитә дә, күпергә кермичә, шыңшып хуҗасы янына кире китә. Дию, аңа камчысы белән генә селтәп, атына атланган килеш күпергә барып керә. Күпергә барып керү белән моның аты да шып туктый. Диюнең ачуы килеп атына сугып җибәрә:

— Һәй, ди, нигә куркасың? Әллә монда Таңбатыр килеп яткан дип уйлыйсыңмы, ди, әле ул монда килү түгел, анадан да тумагандыр,— ди.

Диюнең шулай дип әйтеп кенә бетерүе була, бакыр күпер астыннан «тып» итеп Таңбатыр килеп чыга. Килеп чыга да:

— Таңбатыр анадан да туган, килеп тә җиткән,— дип, дию пәрие каршысына килеп баса.

— Килсәң,— ди, дию әйтә,— әллә ни олы гәүдәле түгел икәнсең әле, ди, ике кабып, бер йотарга гына җитәрсең,— ди.

Таңбатыр әйтә:

— Гәүдәсе чуклы булыр, алай тиз генә йота алмассың,— ди.

Дию әйтә:

— Күп сөйләшеп торма, ди, алыш бармы, көрәш бармы? — ди.

— Алыш агаң башына булыр, әйдә көрәшик,— ди.

Шуннан көрәшергә тотыналар да, алыша алмыйча шулкадәр озак йөриләр болар, шул тирәләр бөтенләй казылып чокырга әйләнеп бетә. Йөри торгач, диюнең хәле бетә башлый. Шул вакытта Таңбатыр моны күтәреп сала да, кылычын суырып алып, диюне

А-120

тураклап, әрдәнә итеп өеп куя. Шуннан соң бу, диюнең атына атланып, аның сараена китә. Диюнең әлеге каравылчысы моңа каршы йөгереп чыга:

— Хәзер куркыр кешем юк, әйтергә ярый, ди, мин фәлән патшаның олы кызы идем, мине бу дию пәрие урлап алып киткән иде, зинһар, мине монда калдыра күрмә, алып кына кайта күр үзең белән,— ди.

Таңбатыр әйтә:

— Без өч агай-эне сезне эзләргә дип чыккан кешеләр,— ди. Патша биргән язуны кесәсеннән чыгарып күрсәтә.

Патша кызы шатлыгыннан нишләргә белми. Таңбатыр әйтә:

— Атаңның вәгъдәсе буенча, син минем олы абыйга булырга тиешсең, хәзергә шушы бакыр сарайда торып тор, кайтышлый мин сине кереп алырмын,— ди.

Өч көн ял иткәннән соң, юлга чыгар алдыннан, Таңбатыр сорый теге кыздан:

— Синең сеңелләрең кая, аларны ничек эзләп табарга? — ди.

Кыз әйтә:

— Дию пәрие мине бик каты тотты, беркая да чыгармады. Минем барып күргәнем юк, уртанчысына хәтле җиде тәүлек юл булырга тиеш,— ди.

Таңбатыр, кызга исәнлек-саулык теләп, юлга чыгып китә. Тау-ташлар үтеп, җиде тәүлек киттем дигәндә, барып җитә бу бер көмеш сарайга. Көмеш сарай кояшта ялт итеп тора икән, ди. Барып керү белән, көмеш атка атланган, көмештән койган киемнәр кигән бер солдат каршылый моны. Туктата. Таңбатыр янына килеп әйтә бу:

— Әй адәми зат, ди, син монда ялгышып кына килеп кергәнсеңдер, исән-сау чакта чыгып кит моннан, хуҗам кайтса, ашар сине, бер генә йотар,— ди.

Таңбатыр әйтә:

— Хуҗаң тизрәк кайтсын иде әле, ди, әллә ул ашар, әллә мин аның башына җитәрмен, ди. Менә минем җиде тәүлек буена рәтләп ашаганым юк, иң элек син миңа ашарга китер,— ди.

— Сиңа ашатырлык бернәрсәм дә юк, хуҗама дип әзерләп куйган ике түшкә үгез итем, ике мич ипием, ике мичкә әче суым гына бар,— ди.

— Ярар, хәзергә җитеп торыр, китер әле шуларны,— ди.

— Хуҗама ничек дип җавап бирермен икән соң? — ди.

— Курыкма, ди, хуҗаңа ашап-эчеп торырга да туры килмәс,— ди егет.

Шуннан соң теге көмеш киемле солдат Таңбатырга ашарга-эчәргә китереп бирә. Таңбатыр, туйганчы ашап-эчкәннән соң, яхшылап кына сораша бу солдаттан:

— Хуҗаң кайчан кайта? — ди.

— Ул иртәгәләргә кайтып җитәргә тиеш,— ди.

— Кайсы яктан кайта ул? — ди.

— Менә шушы сарай артыннан ага торган елга аркылы бер көмеш күпер булыр, ди, һәрвакытта шул көмеш күпер аркылы кайта ул,— ди.

— Мин хәзер ял итәргә ятам, хуҗаң кайтып җитәрәк мине уятырсың, ди, әгәр дә бик каты йоклап китсәм, менә шушы без белән чигәмә кадарсың,— дип, солдатка бер без чыгарып бирә дә йокларга ята бу.

Таңбатыр бер көн, бер төн йоклаганнан соң дию пәриенең кайтыр вакыты җитә. Дию пәриенең якынлаша башлавын сизеп, теге каравылчы солдат уята башлый. Уянмый гына бит теге. Уята алмый аптырагач, утырып елый бу моның янында. Без белән чәнчер иде, кызгана, башкача уята алмый. «Инде без белән чәнчеп уятыйм», дип кенә торганда, Таңбатыр, моның елавын ишетеп, уянып китә.

Солдат әйтә:

— Тизрәк тор, ди, югыйсә дию пәрие кайтып җитә инде, кайтып керсә, икебезне дә харап итәр,— ди.

Таңбатыр тиз генә тора да, кылычын алып, теге көмеш күпер астына барып ята. Күп тә үтми, җил-давыллар чыгарып, дию пәрие кайтып та җитә. Иң элек моның эте күпергә килеп керә. Бер-ике генә атлый да эт шыңшып хуҗасына таба кире чаба. Дию пәриенең моңа бик каты ачуы килеп, камчысын селти дә көмеш күпергә чабып кереп китә. Күпер уртасына җитүгә, ат «шып» туктый. Дию атына тагын бер сугып җибәрә, аты урыныннан да кузгалмый моның.

— Их син,— ди, дию,— котың чыккан икән, ди, әллә син монда Таңбатыр килеп җитәр дип уйлыйсыңмы? Таңбатыр анадан да тумаган әле,— ди.

Диюнең шулай дип әйтеп бетерүе генә була, Таңбатыр көмеш күпер астыннан килеп тә чыга.

— Таңбатыр анадан да туган, килеп тә җиткән,— ди.

— Килсәң, бик шәп булган,— ди дию,— мин сине ике кабармын, бер йотармын,— ди.

— Йота алмассың, сөягем каты булыр,— ди.

— Ярар алай булса, алыштанмы, көрәштәнме? — ди.

— Алыш агаң башына булыр, әйдә көрәшәбез,— ди Таңбатыр.

Шуннан болар көрәшергә тотыналар. Таңбатыр диюне күтәреп ала да җиргә китереп бәрә, тегенең сөякләре өзгәләнеп-өзгәләнеп китә. Шуннан соң Таңбатыр моның сөякләрен әрдәнә итеп өеп куя да, диюнең атына атланып, солдат янына кайта.

Солдат әйтә:

— Әй, абый, ди, зинһар, син мине монда калдыра күрмә, ди, мин солдат түгел, шулай киендем генә, мин фәлән патшаның уртанчы кызы идем, син мине үзең белән алып кайта күр,— ди.

— Ярар,— ди егет,— минем уртанчы агама булырсың, ди. Моңарга да патша биргән язуны чыгарып күрсәтә.— Син шушы көмеш сарайда торып тор, ди, мин сине кайтышлый кереп алып китәрмен, хәзер синең сеңелеңне эзләргә китәм,— ди.— Ул кайсы якта, моннан еракмы? — ди.

— Шушы көмеш атка атланып барсаң, моннан җиде тәүлек юл ул,— ди кыз.

Егет көмеш атка атланып китә. Җиде тәүлек дигәндә, теге алтын сарайга барып җитә. Алтын сарай калын стена белән әйләндереп алынган. Алтын капка төбендә алтын кием кигән, алтын атка атланган бер сакчы йөреп тора икән, ди. Таңбатыр килеп җитү белән теге сакчы әйтә:

— Әй, адәми зат, монда нишләп йөрисең, ди, сине бит дию ашар,— ди.

Егет әйтә:

— Әллә ул ашар, әллә мин аның башына җитәрмен, хәзергә минем бик нык ашыйсым килә, тамагымны туйдыр әле син,— ди.

Сакчы әйтә:

— Минем хуҗам өчен хәзерләп куйган өч мичкә әче суым, өч мич ипием, өч түшкә үгез итеннән башка бернәрсәм дә юк,— ди.

— Миңа шушылар җитәр,— ди егет.

— Алай булса,— ди сакчы,— әнә тегендә чуен капка булыр, шул капканы ачып керә алсаң, ашарыңа бирермен,— ди.

Шуннан егет чуен капканы сугып вата да сарайның эченә кереп китә. Сакчы моның

көченә шакката. Бу сакчы, Таңбатырны бер бүлмәгә алып кереп, ашата да эчертә. Ашап-эчкәч, егет сораша сакчыдан:

— Хуҗаң кайчан кайта, кая таба китте? — ди.

— Әнә теге калын урман ягыннан кайта, ди. Анда бер алтын күпер булыр, ди. Дию пәрие, алтын атка атланып, әнә шул күпердән кайтыр, үзенең этен иярткән булыр,— ди.

Егет әйтә:

— Мин хәзер ял итәргә ятам. Хуҗаң кайтыр вакыт җитү белән, мине уятырсың, уянмасам, менә шушы без белән чәнчерсең,— дип, сакчыга бер без бирә.

Егет яту белән йокыга китә. Бер көн, бер төн үтте дигәндә, теге диюнең кайтыр вакыты җитә. Егетне уятып карый сакчы, кая ул, теге кузгалып та карамый. Шуннан соң сакчы бу егет биргән безне алып бот итенә чәнчеп җибәрә, егет:

— Ай, рәхмәт, бик вакытлы уяттың әле,— дип, сикереп тора.

Сакчы шунда утырган мичкәдән бер чүмеч су алып бирә:

— Менә бу суны эчеп кит, көч кертә торган су бу,— ди.

Егет суны эчә. Шуннан соң сакчы, Таңбатырны тагын бер бүлмәгә алып кереп, әйтә тегеңәр:

— Диюнең үзенә килгән кешене өйгә алып кайта торган гадәте бар. Менә монда ике мичкә бар, аның берсендә көч кертә торган су, икенчесендә хәл бетерә торган су, ди, син шуларның урыннарын алыштырып куй,— ди.

Егет мичкәләрнең урыннарын алыштырып куйганнан соң, сакчы белән саубуллашып, чыгып китә дә теге алтын күпер астына кереп ята.

Бервакытны дию алтын атына атланып, этен ияртеп күпергә кайтып җитә. Диюнең эте күпергә кермичә, койрыгын бот арасына кыстырып, кире хуҗасы янына чабып, елаган сыман итә. Диюнең моңа бик каты ачуы килә. Бик нык камчы белән сугып җибәрә дә күпер өстенә кереп китә бу. Ат күпер уртасына килеп җитү белән «шып» туктый. Дию атын сугып та карый, ат бер генә адым да алга атламый, ди. Шуннан соң дию, атына бик каты ачуланып:

— Нәрсә син, әллә монда Таңбатыр килер дип куркасыңмы, Таңбатыр анасыннан да тумагандыр әле,— ди.

Дию пәриенең шулай дип әйтүе генә була, Таңбатыр күпер астыннан килеп тә чыга:

— Таңбатыр анасыннан да туган, килеп тә җиткән,— ди.

Дию пәрие әйтә:

— Мин сине бик олы гәүдәле дип уйлаган идем, син бик бәләкәй икәнсең. Сине ике кабарга, бер йотарга була икән,— ди.

— Ашыкма, тамагыңа торыр,— ди.

Шуннан соң дию әйтә:

— Алай булгач, көрәштәнме, алыштанмы? — ди.

— Алыш атаң башына булсын, көрәш синең башыңа булсын, мин синең агаларыңны үтереп бетердем инде,— ди.

Шуннан тотыналар болар көрәшергә. Көрәшәләр-көрәшәләр, бер-берсен җиңә алмыйлар. Көчкә көч туры килә инде боларның. Бик озак йөри торгач, Таңбатыр тегене арыта. Шуннан соң дию пәрие сизенә башлый. «Тукта, ди, бу минем хәлне бетереп үтерә күрмәсен, өйгә кайтып ял итим әле мин»,— дип уйлый. Әйтә Таңбатырга:

— Өйгә кайтып бераз ашап-эчик, ди. Аннан соң яңадан көрәшергә тотынырбыз,— ди.

Дию пәрие сараена кайтып ашыйлар-эчәләр болар. Дию пәрие мичкәләрнең алыштырылуын белмичә көч кертә торган су урынына көч бетерә торган мичкәдәге суны эчә. Таңбатырга көч кертә торган суны бирә. Шуннан соң болар китәләр яңадан теге күпер янына. Барып җитәләр.

Дию әйтә:

— Алыштанмы, сугыштанмы? — ди.

— Алышудан курыксаң, сугышырга да була, әйдә сугышабыз,— ди.

Күпер янындагы аланга төшәләр. Шуннан шобага салалар — кемгә алдан сугарга. Дию пәриенә алдан сугарга килеп чыга. Иң элек дию пәрие китереп бәрә Таңбатырга. Таңбатыр тубыгыннан җиргә кереп бата. Аягын җирдән тартып алып, Таңбатыр сугып җибәрә тегеңәргә — дию пәриенең аягы тезеннән җиргә бата. Дию пәрие торып сугып җибәрә, Таңбатыр тезеннән бата. Таңбатыр яңадан сугып җибәрә, дию пәрие биленнән бата. Дию пәрие кабалана-кабалана чыга да Таңбатырга китереп суга, Таңбатыр биленнән бата, чыгарга тырышып карый, чыга алмый.

Дию әйтә:

— Чык-чык, борча, ди, нишләп ятасың туфракта? — ди.

— Кайгырма, ди, борча чыгар ул, менә син ничек чыгарсың икән! — ди.

Шулай ди дә, бөтен көче белән бер селкенеп җибәрүе була, сикереп чыга бу. Дию каршысына килеп баса да кизәнеп диюгә сугып җибәрә, дию муеныннан җиргә бата. Шуннан Таңбатыр әйтә:

— Чык, күсәк, ди, нишләп ятасың анда? — ди.

Дию пәрие тәмам хәлдән тая. Таңбатыр кылычын алып дию пәриенең башын өзеп төшерә, гәүдәсен өстерәп чыгарып вак-вак итеп тураклый да әрдәнә итеп өеп куя.

Таңбатыр, диюнең атына атланып, алтын сарайга кайтып китә. Моны теге сакчы бик шатланып каршы ала:

— Әй, егет, ди, мин сакчы солдат түгел бит, мине шулай киендерделәр генә, мин фәлән патшаның кече кызы бит, ди, мине дә алып кайт, үзеңнән калдырма,— ди.

Таңбатыр моңа патша язуын бирә дә әйтә:

— Мин сезнең апаларыгызны да коткардым инде, ди. Апаларың абыйларыма чыкмакчы булдылар, риза булсаң, син минем җәмәгать булырсың,— ди.

Риза булышалар да үзләренчә шунда ук туй да ясап алалар. Берничә көн кунак булып ял иткәч, туталары янына кайтырга хәзерләнәләр. Юлга чыгар алдыннан егет әйтә:

— Әй, бу алтын йортлар әрәм булып калалар бит,— ди.

Кыз әйтә:

— Син алар өчен кайгырма, җае табылыр,— ди.

Шуннан соң болар, юл кирәкләрен алып, атка атланып чыгып китәләр. Бераз киткәч, кыз алтын сарайга таба әйләнеп кульяулыгын селтәгән иде, алтын сарай алтын күкәй булып тәгәрәп килеп керде кызның кулына. Кыз бу алтын күкәйне яулыкка төрә дә егеткә бирә:

— Мә, син сакла инде моны,— ди.

Баралар-баралар болар, җиде тәүлек үтте дигәндә барып җитәләр теге көмеш сарайга. Патша кызлары елашып күрешәләр. Өч көн, өч төн көмеш сарайда кунак булганнан соң, хәзерләнеп, юлга чыгып китәләр. Бераз җир баргач, патша кызы көмеш сарайга борылып кульяулыгын селкеп җибәргән иде, көмеш сарай көмеш күкәйгә әверелеп

моның кулына тәгәрәп килеп керә. Патша кызы көмеш күкәйне яулыгына төреп егеткә бирә дә әйтә:

— Мә, ди, бусын да син сакла инде,— ди.

Баралар-баралар, ди, болар, җиде тәүлек киткәч, барып җитәләр теге бакыр сарайга. Барып керәләр. Апалары белән елаша-елаша күрешәләр. Апалары сый-хөрмәт күрсәтә боларга. Бу сарайда өч көн, өч төн кунгач, болар, хәзерлеген күреп, юлга чыгып китәләр. Бераз җир киткәч, кече сеңелләре бакыр сарайга таба карап кулъяулыгын селкеп җибәрә. Теге сарай бакыр күкәй булып йомарлана да тәгәрәп килеп керә кызның кулына. Патша кызы бакыр күкәйне яулыгына төреп егеткә бирә:

— Мә, ди, син сакла инде боларны,— ди.

Таңбатыр бакыр күкәйне дә алып кесәсенә салып куя.

Ярар. Китәләр болар. Бара-бара килеп җитәләр теге кое төбенә. Кое төбенә җитү белән Таңбатыр арканның очыннан тотып селкетә инде, «тартып чыгарыгыз безне», дип белдерә. Иң элек олы апалары арканга тотына. Аны тартып чыгаралар. Ул килеп чыгу белән Таңбатырның абыйлары үзара сугыша башлыйлар: «Бу миңа да, бу миңа»,— дип.

Патша кызы әйтә:

— Мин олы апалары, иң олыгызга булырмын, без өч кыз, өчебез өчегезгә булырбыз, сугышмагыз,— ди. Боларга арканны төшерергә куша.

Арканны төшереп уртанчы кызны тартып чыгаралар. Уртанчы кыз чыккач болар тагын сугышырга тотыналар. Уртанчы кыз апасыннан матуррак икән.

Кызлар әйтәләр:

— Сез алай сугышмагыз, әле анда безне табып, дию кулыннан коткарган энегез бар. Безнең сеңелебез бар, аларны кое төбеннән тартып чыгарыгыз,— диләр.

Сугышып аргач тегеләр арканны төшереп җибәрәләр. Аркан төшү белән кыз әйтә:

— Башта сине тартып алсыннар, ди, үзең чыккач син мине тартып чыгарырсың, югыйсә алар сине тартып чыгармаслар,— ди.

Егет әйтә:

— Юк, ди, мин синең үзеңне генә монда җир астында калдыра алмыйм, башта син чык, аннан соң гына минем чыгу турында уйларга булыр,— ди.

Егет аркан очын элмәкләп бәйләп кызны шуңа утыртып чыгарып җибәрә. Кызны тартып алалар да, матурлыгын күреп, яңадан сугыша башлыйлар болар.

Кыз әйтә:

— Мин барыбер сезгә булмыйм, ди, сезнең энегез Таңбатыр белән сүз куештык бергә булырга,— ди.

Кызлар өчәүләп тегеләрне кыстыйлар Таңбатырны тартып чыгарырга. Ярар, тегеләр арканны төшереп җибәрәләр. Таңбатыр арканга ябышып чыгып җитәм генә дигәндә абыйлары арканны кисеп җибәрәләр. Таңбатыр кое төбенә төшеп китә. Кызлар елашып калалар. Таңбатырның агалары юлга чыгарга җыена башлыйлар.

Ярар, инде без Таңбатырга килик. Таңбатыр, кое төбенә килеп төшкәч, бик озак вакытлар һушына килә алмый ята. Өч көн, өч төн ятканнан соң бу әкрен генә кузгалып торып китә. Йөри-йөри бу, йөри торгач тагын теге тычканга очрый. Тычкан моның каршысына килеп чыгып тилпенеп җибәрә дә кеше сурәтенә керә:

— Нихәл, Таңбатыр, тагын да бу хәлгә төшкәнсең икән син,— ди.

Таңбатыр әйтә:

— Шулай булды шул, ди, җир өстенә чыгарга юл эзләп йөрим дә, бер дә җай юк әле,— ди.

— Сиңа моннан чыгарга бу тирәдә бер хәйлә дә табып булмас,— ди тычкан.— Теге соңгы дию белән сугышкан җирдән узып китәргә тырышып кара, шул тирәдән узып китә алсаң, бер-бер хәл булыр, ди. Шул алтын күперне узгач, булыр бер биек тау, шул тауда йөрер ике кәҗә тәкәсе, ди. Ул кыр кәҗәләренең берсе ак, берсе кара булыр. Алар бик йөгерек булырлар, ди. Менә шул ак кәҗә тәкәсен тотып атлана алсаң, ул сине җир өстенә чыгарып куяр, ди. Ә кара кәҗә тәкәсен тотсаң, ул сине йә үтерер, йә тагын да тирәнгәрәк алып төшеп китәр, ди. Аны тота күрмә,— ди.

Шуннан Таңбатыр, тычканга рәхмәтләр әйтеп, әлеге юл белән китә. Атна китә, ай китә. Бара торгач килеп җитә, ди, бу теге тауга. Кәҗә тәкәләрен эзләп табып, шуларның агын куып йөри башлый бу. Артыннан җитеп тотып алыйм гына дигәндә, кара кәҗә тәкәсе арага килә дә керә, тотарга җайсызлый. Күп йөри торгач, ак тәкәне эләктереп ала. Тотылгач, тәкә сорый инде моннан:

— Йә, егет, син мине тотарга тырыштың инде, ди, нинди теләгең бар иде соң? — ди.

— Теләгем шул, мин якты дөньяга чыгарга телим,— ди.

Ак кәҗә тәкәсе әйтә:

— Мин сине якты дөньяга чыгарып җиткерә алмам анысы, шулай да чыгу юлына төшереп җибәрермен, теге ягын синең үзеңә эзләп табарга туры килер,— ди.

— Озак барырга туры килерме соң безгә? — ди егет.

— Байтак җир барасы булыр, ди, син менә миңа атлан, ди, йом күзеңне, мин әйтмичә ачма,— ди.

Шулай ди дә кыр кәҗәсе җилеп китә, ди, егет көчкә генә тотынып утыра, ди, моның өстендә.

Азмы-күпме вакыт үткәндер, теге кәҗә тәкәсе Таңбатырга әйтә:

— Ач күзеңне,— ди.

Күзен ачып җибәрсә, егет күрә: тирә-як яп-якты. Бик шатлана бу. Ак кәҗә тәкәсе әйтә егеткә:

— Вакытыңны үткәрмә, ди, әнә тау битеннән бер юл китәр, шул юл белән барсаң югалмассың,— ди. Шулай ди дә күздән дә югала.

Ярар, Таңбатыр китә шул юл белән. Бара-бара бу, бара торгач барып чыга бер ут ягылган урынга. Килеп көлне актарып карый, көл астыннан бер бөтен ипи чыга. Ипи өстенә «Таңбатыр» дип язылган була. Шуннан соң бу: «Әһә, мин болар артыннан төшкәнмен икән, өйгә таба кайтам икән»,— дип уйлый. Ипине алып ашый да шул урында ятып ял итеп ала. Торып китә бу, бара торгач янә килеп җитә ут ягылган урынга. Көлне актарып карый, моннан да бер бөтен ипи килеп чыга. Ипи пешәр-пешмәс кенә булып, җылы гына булып ята, ди. Ипине алып ашый да, ял итеп тә тормыйча, юлга чыга бу. Бара торгач, килеп җитә кешеләр туктап, утлар ягып, ашлар пешереп утырган бер җиргә. Көлне актарып карый, моннан бер чи ипи чыга. Әле ипи диярлек тә түгел, камыр көе генә, пешеп тә җитмәгән. «Әһә, ди, боларның артыннан җитеп киләм, ахры»,— ди. Китә бу, ару-талуны да белми. Бара торгач, барып җитә урман буендагы аланлыкка. Бу барып җиткәндә, абыйлары ял итәргә туктап, шалашлар корып кына торалар икән. Бу килеп җитү белән, абыйлары аптыраашта калалар; кызлар елаша-елаша Таңбатырны каршы алып, аңа сый-хөрмәт күрсәтәләр. Кич җиту белән, өч агай-эне өч җиргә йокларга яталар. Таңбатыр йокыга китү белән, агалары үзара киңәшләшә, сөйләшә башлыйлар, ди.

Олы абыйсы әйтә:

— Без моңа бик күп зыян эшләдек, ул барыбер бездән үчен алмый калмас,— ди.

Уртанчы абыйсы әйтә:

— Яхшылык көтмә инде син аннан, ди, ничек кенә итеп булса да котылырга кирәк,— ди.

Сөйләшеп сүз беркетәләр дә Таңбатыр яткан шалашның ишегенә аркылыга кылыч куялар, үткен ягы белән шалашка каратып. Төн уртасы җиткәч, болар:

— Харап итәләр, талыйлар! — дип, яман тавыш белән акыра башлыйлар.

Таңбатыр йокысыннан уянып шалаштан йөгереп чыгыйм дигәндә үткен кылычка килеп бәрелә дә ике аягын да өздерә. Инде бу кузгала да алмый, шып итеп утыра шунда. Агалары әйберләрен алай-болай җыештыралар да кызларны алып кайтып китәләр. Таңбатырның хатыны инәлеп-инәлеп сорый абыйларыннан: «Мине аның янында калдырыгыз»,— дип, тегеләр, кызның ай-ваена карамыйча, аны көчләп алып кайтып китәләр.

Ярар, тегеләр өйләренә кайта торсыннар, без Таңбатыр янында калыйк.

Таңбатыр ята тегеләрдән янып калган ут янында. Шуыша-шуыша йөреп, аннан-моннан утын-фәлән китерә бу, утны сүндерми тота, юкса эш начар бит.

Көннәрдән бер көнне, моннан ерак түгел генә җирдә бер кеше күренә. Бу кеше киекләр артыннан куып җитә, тик тота алмый, ә үзе тегермән ташы бәйләгән. Таңбатыр моны үзе янына чакырып ала.

Сорый моннан:

— Син монда нишләп йөрисең? — ди.

— Мин сукыр кеше, ди, минем йөгереклектән көнләшеп, агаларым минем ике күземне сукырайттылар да шушы җирләргә китереп калдырып киттеләр,— ди.

— Аягыңа нәрсә бәйләдең соң син? — ди Таңбатыр.

— Күрәсең ич, бәйләмәсәм йөгерүем чамасызга китә,— ди.

Болар шулай сөйләшә-сөйләшә танышалар да икесе бергәләп көн итәргә булалар.

Ике-өч көннән соң болар янына өченче берәү килеп чыга. Бу кулсыз бер кеше икән, ди. Бу да абыйларыннан зыян күргән яшь егет икән, үзе чиксез-чамасыз көчле икән.

Яши башлыйлар болар өчәүләп бик дус булып. Сукыр белән кулсыз ашарга китерә, ә Таңбатыр ашны хәзерләп тора.

Көннәрдән бер көнне болар үзара сөйләшәләр:

— Безгә аш пешерүче табарга кирәк,— диләр.

Китәләр болар шәһәр эзләп, аяксыз сукырга атлана, сукыр аргач, аяксызны кулсыз күтәреп йөртә. Шулай итеп, бик озак вакытлар йөри торгач, бер шәһәргә барып керәләр. Бөтен шәһәр халкы боларны карарга чыга. Шул халык арасында патша кызы да бар икән, ди. Ул ара да булмый, болар шул патша кызын эләктереп алып та китәләр, ди. Куалар болар артыннан, кая ул теге йөгерек артыннан җитү, тегеләрне син күр дә, мин күр.

Кайтып җитә бу өч батыр үзләре торган җиргә. Кызга әйтәләр:

— Без сине үзебезнең сеңелебез кебек кенә тотарбыз. Син безгә аш хәзерләрсең, тик утны гына сүндермә, диләр. Бүтән эш юк сиңа,— диләр.

Болар һәр көнне өчесе дә җәнлек ауларга чыгып китәләр, кыз өйдә кала. Беркөнне шулай кыз ничектер йокыга китә дә уты сүнә. Уянып китә бу, утның сүнгәнлеген күреп, куркуга төшә: «Агаларым ачуланырлар инде мине»,— ди. Йөгереп чыга да, бер биек агач башына менеп, тирә-якларны карый. Еракта-еракта, елтыр-елтыр итеп, тычкан күзе хәтле генә бер ут күренә. Шул утны эзләп китә бу кыз. Бара торгач, килеп җитә бу кечкенә генә бер җир өйгә. Бәләкәй генә ишеген ачып керә. Аның эчендә бер

карчык утыра икән, ди. Бу убырлы карчык икән. Кыз килеп керү белән убырлы карчык сорый кыздан:

— Йә, кызым, килдеңме, ди, нәрсә эзләп йөрисең? — ди.

— И әби, ди, утым сүнде, ут эзләргә чыккан идем,— ди.

— Ярар, кызым, мин сиңа ут бирермен, минем бер кешем дә юк, миңа бик күңелсез, иртәгә мин сиңа кунакка барырмын, икәү иркенләп кенә сөйләшеп утырырбыз,— ди.

— Ярар, әби,— ди кыз, тик син ничек табарсың икән безне,— ди.

— Менә мин сиңа бер чиләк көл бирәм, ди, шул көлне үзең кайта торган юлның ике ягына сибә барырсың, мин шул юлдан, шәт, сезнең янга барып чыгармын,— ди карчык.

Кыз, карчык биргән утны өенә алып кайтып, абыйлары кайтканчы аш-суны хәзерләп куя. Тегеләр ашап-эчеп ятып йоклыйлар да икенче көнне тагын да ауга чыгып китәләр.

Абыйлары чыгып китү белән теге карчык килеп керә бу кыз янына. Бераз утырганнан соң карчык әйтә:

— Балакаем, ди, син минем башымны кара әле,— ди.

Кызның алдына ята, кыз моның башын караган вакытта карчык кызның ботыннан канын суыра икән, ди. Бу карчык кызның канын суыра-суыра да торып кайтып китә. Шуннан соң бу карчык, кызның абыйлары юкта килеп, һәр көнне кызның канын суырып китә торган булган. Кыз көннән-көн ябыга, кибә барып, тора-бара коры сөяккә генә калган, ди. Абыйлары, кызның ябыкканнан-ябыга баруын күреп:

— Сеңелем, соң син нигә болай ябыгасың, сагынасыңмы, чирлисеңме? — дип сорыйлар кыздан.

Кыз әйтә:

— Сагынмыйм да, чирләмим дә, тик болай гына ябыгам,— ди, яшерә инде болардан.

Тора-бара кыз бөтенләй йөри алмый башлый, аяксыз кала. Шуннан соң гына кыз әйтә абыйларына:

— Менә шулай-шулай, ди, утым сүнгәч, мин бер карчыктан ут алып кайткан идем, ди, шул карчык миңа ияләнде, һәр көнне килеп минем канымны суыра,— ди.

Абыйлары, үзара сөйләшеп, бу карчыкны тотып үтерергә булдылар. Шулай сөйләштеләр дә кыз янында сукырны калдырып киттеләр. Сукыр мич башына менеп утыра. Озак та үтми карчык килеп керә дә мич башында утырган сукырны күреп:

— Ә, бу сукыр мине сакларга калдымыни? — дип, сукырны мич башыннан өстерәп төшерә, аның аягын-кулын чәче белән бәйләп, үзе кызның канын суыра-суыра да чыгып китә.

Икенче көнне кыз янында калдыралар кулсызны. Карчык аны да шулай чәче белән бәйләп сала да, кызның алдына ятып, канын суырып китә.

Өченче көнне кыз янында Таңбатыр үзе кала. Кызга әйтә:

— Мин сәке астына кереп ятам, карчык бүген кайсысы калды дип сораса, алар бүген гел кайтмаслар, синнән курыктылар, калмадылар дип әйт, ди. Карчык алдыңа ятып каныңны суыра башлагач кына аның чәчен сәке ярыгыннан төшер,— ди.

Бер заманны карчык килеп керә, бер дә шикләнмичә кыз алдына ятып аның канын суыра башлый. Кыз карчыкның чәчен ярыктан сәке астына төшереп җибәрә. Таңбатыр, карчыкның чәчен тартып алып, сәке астындагы аркылы агачка бәйләп куя да, үзе сәке астыннан килеп чыгып, карчыкны ярырга тотына — кай җирең кычыта! Шул арада моның иптәшләре дә кайтып керәләр. Кулсыз тотына карчыкны типкәләргә, ә сукыр кай җиренә эләксә шунда суга, ди. Карчык бөтенләй эштән чыга. Ялына башлый, ди, боларга:

— Кыйнамагыз, ди, күзсезне — күзле, аяксызны — аяклы, кулсызны — куллы итәм,— ди.

Шуннан болар карчыкны ант иттерәләр. Карчык ант итә. Иң элек йоттыралар, ди, болар кызны. Кызны йотып җибәрә дә китереп чыгара авызыннан, элеккедән дә матур, элеккедән дә чибәр кыз булып чыга, ди бу. Аннан соң сукырны йоттыралар. Сукыр да ике күзле булып килеп чыга, ди. Аннары кулсызны йотып җибәрә, ди. Кулсыз ике куллы булып килеп чыга. Таңбатыр әйтә:

— Карагыз, сак булыгыз, ди, ул мине йотуын-йотар, кире чыгармас, ди. Мине чыгармыйча җибәрмәгез сез аны,— ди.

Теге убырлы карчык Таңбатырны да йотып җибәрә. Көтәләр моны, көтәләр, килеп чыгар дип, карчык космый гына бит. Карчыкны кыйнап та карыйлар, чыгармый. Шуннан соң теге сукырдан күзле булган батыр кылычын ала да карчыкны тураклый башлый. Кискәләп бетерәләр моны, ә Таңбатыр юк. Карыйлар, бу карчыкның бер баш бармагы юк. Баш бармагын эзли башлыйлар, бу баш бармак карчыкның өенә таба китеп бара икән. Тотып алып ярып җибәрәләр — Таңбатыр килеп чыга, элеккедән дә матур, таза булып.

Бу өч батыр бик шатланышып берничә көн бергә торалар да үз илләренә кайтырга булалар. Таңбатыр әйтә:

— Без сеңелкәйне үз иленә илтеп куйыйк башта,— ди.

Бу кызга бик күп бүләкләр бирәләр дә, саубуллашып, теге шәп йөгерә торган батыр, кызны үзенә атландырып, бик тиз генә илтеп куя. Кызны илтеп кую белән, өч батыр дусларча саубуллашып, бергә-бергә торган чакларын онытмаска сүзләр куешып, һәрберсе үз илләренә кайтып китәләр.

Ярар. Таңбатыр, бик күп илләр үтеп, бик күп сулар кичеп, кайтып җитә үз иленә. Патша тора торган шәһәр читендәге бер карт белән бер карчыкка килеп керә. Таңбатыр әкрен-әкрен генә сораштыра башлый:

— Патшаның батырлары кайттымы, нәрсәләр алып кайттылар, патша кызларын таба алганнармы? — ди.

— Патша кызларын табып алып кайттылар,— ди карт,— тик батырларның берсе үлеп калган бугай,— ди.

— Туйлары булдымы соң? — ди.

— Юк әле, ди, менә бер көннән булырга тиеш,— ди.

Шул сүзне ишетү белән бу тиз генә бер игълан чыгарып кадаклый: «Мин, фәлән-фәлән итекче, патша кызлары туйда киярлек читек тегеп бирә алам»,— дип яза. Патша кызлары, моны ишетеп, теге картны эзләп китәләр дә өй алдына чакыртып чыгаралар.

— Бабай, син шулай-шулай дип әйткәнсең икән, син безгә иртәгә иртә беләнгә берәр пар читек тегеп җитештер,— диләр.

— Фәлән хак бирерсез, вакытына җитештерербез,— дип ышандырып алып калалар.

Патша кызлары китү белән теге карт эшләргә утырмакчы була. Ә егет уйлап та карамый. Карт, өлгермәм, дип курка башлый.

Егет әйтә:

— Ят та йокла син, бабай, үзем тегеп куярмын,— ди.

Карт белән карчык ятып йоклый. Төн уртасы килеп җитү белән егет, урамга чыгып, өч күкәйне тәгәрәтеп җибәрә, өчесеннән өч пар читек килә дә чыга. Егет боларны алып кайтып өстәл өстенә кертеп куя. Иртәнчәк карт тора.

Егет әйтә:

— Менә, бабай, ди, мин читекләрне тектем, ди, алырга килсәләр, үзем тектем, дип әйтерсең. Никадәр сорасалар да, мин теккәнне әйтмә,— ди.

Иртә белән тегеләр килеп җитәләр. Картны чакырып чыгаралар.

— Бабай, тектеңме? — диләр.
— Тектем,— ди.
— Йә, чыгар әле,— диләр.
Карт читекләрне чыгарып бирә.
— Менә карап карагыз, ошыймы сезгә? — ди.
Кызлар читекләрне алалар, бик ошый боларга.
— Моны кем текте? — дип сорыйлар.
— Үзем тектем,— ди карт.
Картка акчаны күп кенә итеп бирәләр. Шуннан соң тагын кайтарып сорыйлар болар:
— Йә, бабай, дөресен әйт, кем текте боларны? — диләр, моны кысалар инде.
Теге һаман:
— Үзем тектем,— ди.
Патша кызлары картка ышанмыйлар. Картка әйтәләр:
— Ярар, бабай, без әти белән сөйләшеп туйны чигерәбез, син андый һөнәрле оста булгач, безнең өчебезгә җөйсез өч күлмәк тегеп бир, күлмәкләр иртәгә өлгергән булсын,— диләр.
Карт тагын ышандырып алып кала инде. Алып калмас иде, Таңбатыр, ни эшләргә кушсалар да, алып кал, дип өйрәткән. Карт, бу күлмәкләрне ничек кенә өлгертербез икән, дип чабалана. Егет әйтә:
— Син кайгырма, ят та йокла, бабай,— ди.
Төн уртасы җитү белән шәһәр читенә чыга да теге өч күкәйне тәгәрәтеп җибәрә. Өч күкәйдән өч күлмәк килеп чыга. Алып кайтып элеп куя бу күлмәкләрне. Иртә белән тегеләр килеп җитәләр. Күлмәкләрне чыгарып бирә карт. Патша кызлары шаккатып карап торалар да:
— Бу күлмәкләрне кем текте? — дип сорыйлар, шикләнәләр инде болар.
Карт әйтә:
— Үзем тектем,— ди.
Патша кызлары картка тиешле хакын бирәләр дә:
— Менә без сиңа тагын бер эш кушабыз, болай һөнәрле кеше булгач, син бу эшне дә эшләрсең,— диләр.
Карт нишләсен, теләсә-теләмәсә дә:
— Ярар, әйтеп карагыз,— ди.
Патшаның олы кызы әйтә:
— Иртә белән шәһәр читендә бер бакыр сарай салынган булсын,— ди.
Уртанчы кызы әйтә:
— Көмеш сарай да салынган булсын,— ди.
Кече кыз әйтә:
— Ике апама ике төрле сарай салынгач, минем өчен алтын сарай салынган булсын,— ди.
Карт каушап кала да соңыннан, теге егеткә ышанып:
— Ярар, тырышып карармын,— ди.
Кызлар кайтып китү белән карт өйгә кереп әйтә:
— Бетте баш, патша кызлары безгә шундый-шундый эшләр кушып киттеләр,— ди. Үзе калтырана, күзләреннән яшьләр килә.— Нишләрбез икән инде, безнең бетүебез шушыдыр,— ди.
Егет әйтә:

— Кайгырма, бабай, ди, син ят та йокла, ди, мин үзем башкарып чыгармын,— ди.

Таңбатыр, төн уртасында чыгып, күкәйнең өчесен өч җиргә тәгәрәтеп җибәрә, өч җирдә өч сарай калкып чыга.

Иртә белән егет бабайны уята:

— Кара әле, бабай, ди, өч җиргә өч сарай салдырып куйдым,— ди.

Бабай бик шатлана, патшаның җәзасыннан котылабыз икән, ди.

Иртә белән патша кызлары иртүк бабай янына килеп җитәләр. Берсеннән-берсе матур өч сарайны күрү белән болар Таңбатырның кайтуын беләләр. Картны чакыртып чыгаралар да әйтәләр:

— Нихәл, бабай, без кушканны эшләдеңме? — диләр.

Бабай әйтә:

— Күрмисезмени? — ди.

— Үзең эшләдеңме, бабай? — диләр.

— Үзем булмыйча,— ди карт, һаман теге егетнең барлыгын сиздерәсе килми, әйтмәм дип сүз биргән бит.

Кызлар ышанмыйча, көлешә-көлешә бабайның сакалларын тарткалап карыйлар. Юк, йолкынмый. Аннары үзара сөйләшеп алалар да:

— Ярар инде, бабай, без сине гаепләмибез, син безгә бу сарайларны салдыручы егетнең үзен күрсәт инде,— диләр.

Бабай теләсә-теләмәсә дә, егетне чакырып чыгара. Патша кызлары Таңбатыр белән елаша-елаша күрешәләр.

Таңбатырның кайту хәбәре патшага да ишетелә. Патша егетне үз янына чакыртып ала. Кызлар әйтәләр әтиләренә:

— Безне дию кулыннан коткаручы егет менә шушы, агалары аңа бик каты зыян итте,— диләр.

Шуннан соң патша, Таңбатырның көченнән куркып, кече кызын, теләсә-теләмәсә дә, аңа бирергә мәҗбүр була.

— Агаларыңны теләсәң нишләт, үзең хөкем ит,— ди.

Таңбатыр агаларын үз янына чакыртып ала да әйтә:

— Сез миңа зур зыян эшләдегез, шулай да астырмыйм, кистермим мин сезне, тик бу шәһәрдән чыгып китегез, күземә күренмәгез,— ди.

Тегеләр башларын иеп чыгып китәләр. Таңбатыр, патшаның кече кызын хатынлыкка алып, кырык көн уен итеп, кырык көн туен иткәннән соң үзенең әти-әниләре янына кайтып тора башлый.

Хәзер дә бик шәп яшиләр икән, ди, болар. Кичә бардым, бүген кайттым.

ДУТАН БАТЫР

Элек заманда бер батыр булган. Үзе бик фәкыйрь икән, ди. Тирә-якта һич ил булмаган. Берәрсе яу чабарга килсә, моңар килеп:

— Безнең малларыбызны таларга килделәр, әйдәсәнә! — дип чакыралар икән.

Бу һәрвакыт өстен чыга, моның шикелле батыр булмый, моңар җиткән кеше юк икән.

Шулай итә-итә, һәр авылдан моңар, яратып, кызларын бирәләр. Моның тугыз хатыны була. Тугыз хатынына тугыз землянка хәзерли, һәркайсы аерым тора. Кызларның аталары үзләренә тиешле малларын да биреп җибәрә, батырның мал да бик үрчи хәзер. Тугыз хатыннан кырык ул, кырык кыз туа. Сиксән баласы була моның. Ә яшь хатыннан бер генә бала туа, аның исеме Дутан була.

Бер көнне сиксән бала җыелып акыллашалар:

— Без бер-беребезгә ярамыйбыз, сезгә булса — кирәк хатын, безгә булса — кирәк тормышка чыгу,— диләр кызлар.

Боларның җылкысын көткән бер карт бар икән. Болар сиксәне сиксән атка атланып китәләр теге көтүче бабай янына. Бабайга әйтәләр:

— Белгән җирең булса, безгә әйт, якын-тирәдә ил дигән нәрсә бармы, без шулай киңәшкә килгән идек,— диләр.

Бабай әйтә:

— Моннан ун көнлек җирдә, төшлекнең уң ягында, бай тирәкле калын урман бар, шунда барыгыз, ди. Атларыгызга дагалар салдырыгыз, коралсыз чыкмагыз,— ди. Дутанга аерып әйтә: — Балам, ди, чын сүземне сиңа әйтәмен, күк айгырның өереннән бер тай туган иде, син шуны тотып мен, башка ярамас сиңа, ди. Ул хасиятле ат булыр. Бу җыелып чыгуыгызның бөтен җәфасы, көлле[1] мәшәкате сиңа гына төшәр,— ди.

Ул вакытта Дутан бик яшь була әле. Шулай да бик батыр булмакчы инде бу. Болар, һәркайсы өйләренә кайтып, атларына дагалар салдырып, үзләренә кораллар әзерләп, ата-аналарыннан рөхсәт сорап, ил эзләргә сәфәр чыгып китәләр.

Барып-барып, теге калын урманны күрәләр. «Бу урманда ни бар икән?» — дип, тизрәк чабып урманга керәләр. Урманда һәр төрле җимешләр бар икән. Атларыннан төшеп, шул җимешләр белән тамак туйдыралар. Болар, ашап-эчеп, һәркайсы үзенең аты янында ятып йоклый.

---

[1] Көлл — бөтен, бөтенесе.

Бу урманда бер Җалмавыз карчык бар икән. Бу Җалмавыз карчык адәм исен сизгәннән соң килеп чыга да, авызын зур ачып, боларны йота. Дутан янына да бара. Йотыйм дип авызын ачканда Дутанның тае тыпырчына башлый, кешни, пошкыра. Атының тыпырчынганын сизеп, Дутан уянып китә. Торып караса як-ягына — туганнары юк, атлары гына калган, каршысында таба шикелле зур күзле бер карчык басып тора. Дутан мылтыгын алып атыйм дигәндә, Җалмавыз карчык әйтә:

— Балам, сабыр ит, атмый тор, ди. Туганнарың миндә, алар бар да исәннәр. Мин сине бер йомышка кушамын, әгәр шул йомышны үтәсәң, туганнарыңны коткарам, ди. Син анда җиде айсыз барып җитә алмассың, ди. Мохит диңгезенең утравында бер патша бар, шуның бер кызы бар. Ул кызның исеме Көнекәй. Аның сылулыгын әйтеп бетерерлек кенә түгел. Шуны алып кайтып бирсәң, котылырсың. Алып кайтып бирмәсәң, туганнарың миндә кала,— ди.

Дутан аның сүзен тыңлап торды да бармакчы булды.

— Мин анда ялгыз баралмам бит, минем туганнарымны исән көе бир миңа, ди. Миңа юлдаш булырлар,— ди.

— Кызны алып кайтам дип сүз бирәсеңме?

— Бирәм.

— Мә, алайса.

Туганнарын һәркайсын косып ташлады бу карчык. Бар да исән-сау.

— Йә, абыйлар,— ди, Дутан әйтә,— бу карчык миңа бер йомыш куша, кайсыгыз миңа юлдаш буласыз? — ди.

Туганнары:

— Без бара алмыйбыз анда,— дип кырт кистеләр.

Дутан үзе генә бармакчы булды. Дутан юл җаен сорый инде хәзер. Юлның кай җирдән барасын өйрәтә Җалмавыз. Аннан соң, кирәк булыр дип, ат башы хәтле ике алтын бирде.

Шулай итеп, чыгып китте Дутан. Аның юлдашы — искән каты җилләр генә инде хәзер. Тай бик шәп чаба моның: көннән-көн атының йөрешенә хәйран калып бара. «Атым беренче булачак икән»,— дип уйлый.

Бер ай тулды дигәндә, зур бер үзәнсу урынга килеп җитә. Шул үзәнсу җирдә су буйлап барса, йөзтүбән яткан бер кешегә туры килә. Килеп җитеп, тегеңәр иелебрәк сәлам бирде. Теге бабай булган кеше икән, баш калкытып сәламен ала.

— Бабай,— ди, Дутан батыр әйтә,— бу җирдә ялгызың нишләп ятасың? — ди.

— Безнең авылның мәкамы[1] шушы иде,— ди, карт әйтә,— бер көнне яу килеп илемне чапкан, ди. Мин ауда идем, кайтып килсәм — илем юк. Авылымның урынын ташлап китәсем килмәде, ди. Аннары минем ятуымның бер хикмәте шул, ди, җир астында бер хан, кызын биреп, туй итә, шуны тыңлап ята идем әле мин, ди. Үзең монда нишләп йөрисең соң? — ди.

Дутан батыр әйтә:

— Миңа Җалмавыз карчык бер йомыш кушты, патша кызын алып кайтырга барам мин,— ди.

— Алай булгач, ди, монда ялгыз ятканчы, мин дә сиңа юлдаш булам,— ди.

Болар, берсе атлы, берсе җәяү, сөйләшеп баралар. Дутанның күңеле хушланып китте хәзер.

---

[1]Мәкам — урын, тора торган урын.

Китеп-китеп тагы бер ай тулган вакытта бер кешегә юлыгалар. Бу кешенең кулында мылтыгы бар, үзе югарыга карап утыра. Барып сәлам бирәләр.

— Син нинди кешесең, ялгыз җирдә утырасың? — диләр.

Бу кеше әйтә:

— Минем авылымны яу чабып китте, менә шулай ялгыз калдым инде, ди. Кичә төш вакытында бер үрдәк аткан идем, ди, мылтыгымның угы бу үрдәкне югары ук алып менеп китте, ди. Бүген шуны көтеп утырам әле, кайчан төшәр дип әйтеп, ди. Ни сәбәптән монда килеп чыктыгыз? — дип, ул да сораша инде.

Шулай сөйләшеп утырган заманда үрдәк килеп төшә. Үрдәкнең җонын йолкып, чистартып, пешереп ашыйлар.

Үрдәк атучы әйтә:

— Монда ялгыз ятканчы, мин дә сезнең белән барамын, кызыклар күреп кайтырмын,— ди.

Болар, икәү җәяүле, бер атлы булып, тагын кузгалып китәләр. Китеп-китеп бер ай тулганда, бер түбәдә җәяүле бүре куучы кешегә очрыйлар. Ике аягына казан чаклы ике таш бәйләгән. Шул таш бәйләгән көе теге бүрене тотып ала бит. «Бу нинди кеше бу?» — дип, моңа хәйран калалар. Бу кешенең янына баралар. Карасалар, егерме яшьләрендә бер матур егет икән бу.

— Син нинди кеше, диләр, аягыңда ташың бар көенчә шулай йөгереп киек тота аласың икән,— диләр.

— Миннән сорасагыз,— ди, теге егет әйтә,— минем атым Җилаяк, ди. Таш бәйләп йөгермәсәм, кая киткәнемне һич белмим, югалып китәмен мин, ди. Бу җирдә мин очкан коштан башканы уздырмыйм,— ди.

Дутан да үзенең хәлен сөйләп бирде. Юлдан үзенә ике иптәш табылганын да әйтте.

— Алай булгач,— ди, Җилаяк әйтә,— мин дә сезнең белән барып, ил күреп, кызыклар күреп килермен,— ди.

Бу да иярде. Өч җәяүле, бер атлы булып, баралар инде болар.

Китеп-китеп, тагын бер ай булды дигәндә, тау араларына барып керәләр. Күрәләр бер кеше: аның баш түбәсендә һәртөрле кошлар очып йөри. Кошларның барысын үзенә караткан бер дивана шикелле була бу кеше. Аңар да борылып сәлам бирәләр.

— Син тау арасында ялгызың нишләп йөрисең? — диләр.

Ул да авылын яу чабып киткәнлеген, шул тау арасын ташлап китәргә кыймый йөргәнлеген әйтә.

— Үзем ялгызмын, сөйләшергә кешем юк, бер нәрсә белән күңел ачмыйча булмый бит, ди. Кошларны үземә каратып, шулар белән күңел күтәреп йөримен шулай,— ди.

Болар да әйтеп бирделәр баштанаяк хәлләрен.

— Ялгыз җирдә торганчы, мин дә сезнең белән барыйм,— дип, ул да иярә.

Тагы китәләр болар, дүрт җәяүле, бер атлы.

Китеп-китеп тагын бер ай тулганда, бер тау буйлап баралар. Бер як — урман. Имәнлек. Урманнан чал сакаллы бер кеше килеп чыга. Ул Дию-чал икән. Бер озын имәнне бөтен буе белән җилкәсенә күтәргән, икенче кулына зур тегермән ташын алган. Моңар дә сәлам бирәләр.

— Бабай, нишләп йөрисең болай? — диләр.

— Моннан түбән бер су бар, шул су буенда минем өем бар, тегермәнче мин, ди. Ташу вакытында шәп ташу килеп, тегермәннең ташын ваттырды, орчыгын сындырды, ди. Ун көннән бирле бер тауда тегермән ташы ясадым, ди. Ике килеп йөргәнче дип әйтеп,

кайтышлый урманга кердем дә орчыкка дип имән алып кайтып киләм, ди. Балалар бар барын да, яшьрәкләр әле, ди. Әйдәгез минем белән өйгә, ашыйк-эчик,— ди.

Барсалар, ун-унбиш өйле генә авыл икән. Диюләр авылы.

— Мин үз хәлемне әйттем,— ди, карт,— сез үзегез ничек килеп чыктыгыз монда? — ди.

Дутан да үзенең хәлен сөйләп бирә.

— Алай булгач,— ди, карт әйтә,— мин дә сезнең белән барып, кызыклар күреп кайтыйм әле,— ди.

Эшне балаларына тапшыра да ул да китә болар белән.

Болар биш җәяүле, бер атлы булып тагы чыгып киттеләр.

Инде тагы бер ай тулганда, юл буенда бер карача[1] гына өйгә туры киләләр. Хәзер теге шәһәр дә ерак түгел инде. Бер фәкыйрь генә агалы-сеңелле кешеләр икән болар. Өсләрендә күлмәкләре дә юк. Чәй кайнатып бергә ашыйлар-эчәләр, монда кунарга туры килә боларга. Теге сорый инде:

— Сез нинди кешеләрсез, ди, кая барасыз болай? — ди.

Дутан әйтә:

— Шушы шәһәр патшасының ялгыз кызы бар икән, ди, шуны алмакка барамын,— ди.

— Ул сәфәрдән,— ди, теге кеше әйтә,— кире кайт син, ул шәһәрне хәзер ун меңле яу камап алды,— ди.

— Мин,— ди, Дутан әйтә,— җиде айлык юл килеп, яудан куркып кире кайта алмыймын,— ди.

Патша кызы шул көндә төш күрә. Болар монда йоклап ятканда патша кызы Көнекәй шушы Дутанның шәһәргә килеп кергәнен, диюләр, пәриләрнең аңардан куркып качканын күрә. Шулай итеп, куркынып уянып китә, янып-пешеп. Һич дөньяга чыкмыйча бер шәп бакчада ята икән ул кыз иптәш кызлары белән. Көнекәй иртә торып үзенең бертуган агасына килә. Агасы сорый:

— Нигә килдең, сеңелем? — ди.— Син дөньяга чыгып йөрми торган идең,— ди.

— Төшемдә алты кеше күрдем, берсе атлы, бишесе җәяүле, ди, шул кешенең атын күреп исләрем китте, ди, әле дә булса кешнәгәне колакларымнан китми, ди. Алтавысы ун мең гаскәргә торырлык кешеләр. Мине алмага килә ул,— ди.

Агасы әйтә:

— Сабыр ит, сеңелем, күргән төшкә мактанып йөрмик әле, ди. Менә дошман явы бар бит әле. Көчен сынарбыз ул егетнең, эшкә кушып карарбыз,— ди.

Кыз, абыйсының сүзенә сөенеп, торган җиренә кайтып китә.

Шул көннәрдә ун мең дошман гаскәре бу шәһәрне камап алдылар. Инде ватабыз-җимерәбез дип, сугыш кормакчы булалар. Шунда бөтен шәһәр халкының куркуга калганын күреп, патша үзенең кызына хәбәр җибәрә:

— Кызым, ди, яхшы атлар җигеп бер чыгып күрен инде, иптәш кызларың белән,— ди.

Патша кызы яхшы атлар җиктереп, үз янына бер-ике иптәш кызын утыртып урамга чыга. Кызның матурлыгы болыт астыннан чыккан кояш шикелле. Килеп чыкты, тегеләргә күренде. Килгән яу патшасының Көнекәйгә күзе төшеп гашыйк булды. Шуннан соң кызның атасына әйтә:

— Малыңа тимим, шәһәреңне ватмыйм, гаскәреңне кырмыйм, миңа кызыңны гына бир,— ди инде.

Патша, халыкны коткару өчен, бердәнбер кызын бирмәкче була.

---

[1]К а р а ч а — морҗасыз, төннекле өй.

— Кырык көннән соң килеп алырсың, кырык көн вәгъдә сиңа,— ди.

Сугышны ачмыенча, кырык көн вәгъдә белән кайтып китә теге патша.

Дутан батыр, иртән торып, иптәшләре белән шәһәргә керә. Кызның агасы каршы чыгып ала боларны. Өенә алып барып кунак итә. Шунда сеңелесенә дә хәбәр сала: «Төшеңдә күргән кешеләрең килеп җитте, күзең белән килеп бак»,— ди. Кыз әлегедәй, үзенең иптәш кызлары белән, атлар җигеп килә монда. Кыз Дутанны күрә, Дутан кызны күрә. Кызның Дутанга күңеле төшә. Кыз, аны-моны сөйләми, өенә кайтып китә. Хәзер ул Дутанны тели инде. Фәкыйрьләрне җыеп, алтын-көмеш бирә. Әйтә Көнекәй шунда:

— Яу патша миннән өметен өзсен,— ди.

Боларның килгәне патшаның үзенә дә ишетелә инде. Дутан батырны патша үз янына чакырта, бер яхшы өйгә кертә, сый-хөрмәт хәзерли.

— Барыгыз бертуганмы сез, нинди кешеләр сез, кай илләрдән килдегез? — дип сораша болардан.

Дутан шунда әйтә патшага:

— Саригу дип әйткән җир — безнең җиребез, ди; атам — патша,— дип җибәргән була инде.— Атам, ди, төшендә синең кызыңны күреп, гашыйк булган. Кызың шунда адресын язып биргән, ди. Менә шул, әти кушуы буенча, мин Көнекәйне алырга килдем. Көчсез бирергә ризамы, көч беләнме? — ди.

Патша шунда әйтә Дутан батырга:

— Бик яхшы, каената итим дип килгән икәнсең, ди. Минем шәһәремне вәйран итеп[1], малларымны алып китмәкче иде дошманнар, ди. «Шушы кызыңны бирсәң, коткарырмын»,— дип әйтеп әйттеләр алар, ди. Мин, бөтен халык өчен, бер кызымны корбан иттем инде, ди. «Кырык көннән соң килеп алырсың»,— дип әйттем, ди. Менә, балам, сиңа сүзем шул: әгәр барып, шул патшаның башын кисеп алып килсәң, кызым синеке. Яу патшасы моннан тугыз көнлек юлда,— ди.

Дутан бармакчы булды. Дутанга җитәккә бу патша үзенең Тел-Коңгыз исемле атын бирде. Дутан батыр, иптәшләрен шушында калдырып, берүзе юлга чыгып китте. Ул көннәрдә Дутан унике яшендә була инде.

Дутан батыр юл белән бара, бервакыт үз атына менә, икенче вакыт Тел-Коңгызга менә. Шулай итеп, бара-бара, яу патшасы шәһәренә барып җитте бу. Шәһәрнең каравылчылары күрде моны. Бер утызлап каравылчы бар икән.

— Патшаның баш шәһәре шушымы? — ди Дутан.

Тегеләр сорашалар:

— Анда ни йомышың бар синең, син нинди кеше? — диләр.

Дутан әйтә:

Мин үзем яшь баламын,
Уттай дөрләп янамын,
Чыгарыгыз монда патшагызны,
Башын кисеп аламын,—

дип, бер шигырь дә кыстырып куя инде шунда.

Бу сүзгә ачулары килеп, моны камап алдылар. Дутан батыр утызлап каравылның бер читеннән керде, ач бүре шикелле ашап, икенче читеннән килеп тә чыкты. Калганнары патшага барып әйттеләр:

---

[1]Вәйран итү — вату, җимерү.

— Килде безгә бер бала: «Чыксын монда патшагыз, башын кисеп аламын»,— дип әйтә.

Патшаның бик ачуы килде. Тагы ике йөзләп гаскәрен чыгарды:

— Камап алыгыз, тереләй тотып китерегез! — диде.

Ике йөз гаскәр чыгып, төрлесе төрле яктан камап алды. Кайсы ук ата, кайсы элмәк ыргыта. Дутан батыр эләкми. Күз ачып йомганчы каннарын судай агызды. Кайтып әйтәләр:

— Безнең аңа чыдар хәлебез юк, тере кеше бик аз калды, үзеңне чакыра,— диләр.

Патшаның бик ачуы килеп, каһәрләнеп, үзе чыга. Угын-җәясен алып, яхшы атка атланып килеп чыкты. Патша кычкыра:

— Син нинди кеше, әҗәлеңне сагынып килдеңмени? — ди.

— Үнәрең[1] булса, күрсәт,— ди, Дутан батыр әйтә,— мин курка торган җан түгел,—ди.

Патша, ук-җәяне төзәп, бер ук атты балага. Дутан батыр тегенең угын, камчы белән сирпеп, җиргә бәреп төшерде.

— Син аттың, инде хәзер мин атканны карап тор,— диде Дутан.

Дутанның угы, патшаның күкрәгендәге көпесеннән[2] үтеп, аркасына тишеп чыкты. Патша атыннан егылып төште. Дутан батыр, патшаның башын кисеп, хурҗинга[3] салып кайтырга әйләнде.

Тугыз көнлек юлны дүрт көндә кайтып җитә бу. Көнекәй, кайтыр вакыты җитте инде дип, көтеп тора, бер Муракорган дигән түбә бар икән, шуннан кайчан күренер дип. Бервакытны, тузан туздырып, җитәккә алган аты белән Дутан килеп чыга. Кыз шатлыгыннан нишләргә белми. Шәһәргә кайтып кергәнче керфеген какмый, күзен йоммый текәлеп карап торды. Дутан батыр кайтып керде патшаның йортына. Иптәшләре килеп җитте. Сөенешеп күрештеләр. Дутан әйтә:

— Менә, падишаһ-солтаным, күңелең хуш булсын, дошманыңның башын алып кайттым, ди. Вәгъдәңне бозмадыңмы? Мин синең хакыңны үтәдем, инде хәзер син минем хакымны үтә,— ди.

Патша әйтә:

— Кызым синеке, ди. Кызымның мәһәре шул булсын, базардан бик яхшы йөз байтал[4] алып килеп бир,— ди.

Дутан батырның алтыны бар иде; бер кисәк алтын биреп, иптәшләрен җибәрә:

— Бар, ди, яхшы байталлар алып килеп бирегез шуңа,— ди.

Алып кайтып бирәләр. Инде хәзер патша туйга хәзерләнә. Аның бер бозык вәзире бар икән, ул вәзир: «Патша кызын миңа бирер әле, миннән башка кемгә бирсен»,— дип йөри икән. Шул бозык вәзир әйтә патшага:

— Бу ялгыз йөргән юлаучыга йөз байталга кыз сатып, ди, даныңны бөтен дөньяга фаш итәсеңме? — ди.— Мин сорашып белдем, аның атасы патша булмаган, ди. Фәкыйрьнең бер фәкыйре икән. Ничек тә булса алдарга кирәк, нитәргә кирәк, бирмәскә кирәк,— ди.

Дутан батыр бер иптәшен җибәрә:

— Патшага әйт, безне кичектермәсен, минем ачуымны китермәсен,— ди.

Патша җавап бирә:

— Моны патша туе дип әйтәләр, ашыкмасын, сабыр итсен, ди. Туй булгач күп халык җыелырга тиеш, атлар ярышырга,мәйдан корып, көрәшчеләр бил алышырга тиеш,—ди.

---

[1] Үнәр — һөнәр.
[2] Көпе (көбә) — металл боҗраларны бер-берсенә кертеп эшләнгән борынгы сугыш киеме.
[3] Хурҗин — асылмалы сумка.
[4] Байтал — яшь бия, өч яшьлек бия.

Шуннан мәйдан җыела. Көрәшчеләр килә. Ат җибәрәләр өч көнлек җиргә. Патша үзе өч йөз баш ат җибәрә. Дутан да китә. Бер түбәдән иң элек Дутан килеп чыга. Мәйданга кереп атыннан төшә. Бик күп вакыт үткәч, патша атлары да килә башлый. Шунда Дутан батыр әйтә патшага:

— Ниең калды инде хәзер, дөресен сөйлә, ди, юк-бар сүзгә алданма, сине алдаучылар бар, минем канымны бозма син,— ди.

Патша бер көрәшче батырны чыгара. Барак дигән батыр, имеш, бу. Дутан батыр Дию-чалны чыгара. Икәвесе көрәшергә тотыналар. Дию-чал Баракны алып ыргыткан-да теге бил тиңентен комга керә.

Дутан әйтә шунда патшага:

— Күңелең булдымы? — ди.

Патша әйтә:

— Тамашага күп халык җыелган, җәяүлеләрне дә ярыштырыйк,— ди.

Патшаның бер йөгерешче карчыгы бар икән. Тагы да өч көнлек юлга җибәрәләр. Дутан куша Җилаякны. Өч көнлек җиргә барып җитәләр карчык белән Җилаяк. Барып утыралар. Ял итәләр.

Җилаяк әйтә:

— Әби, ди, бик сусадым мин. Су да алмадык, ичмасам,— ди.

Карчык әйтә:

— Сусасаң, миндә су бар,— ди.

Ике шешә эчемлек алып барган икән теге карчык.

— Эчеп җибәр, балам, җәяүлегә яхшы була ул,— ди.

Җилаяк, аны-моны белмичә, бер шешәсен күтәреп эчеп җибәрә.

— Туйдыңмы? — ди, карчык әйтә.

— Әби,— ди, Җилаяк әйтә,— туеп җитә алмадым әле,— ди.

— Менә тагы бер шешәсе бар,— ди.

Анысын тагын эчеп җибәрә. Җилаяк шунда исерә дә егыла. Кич булган икән, карчык тора да йөгерә башлый хәзер. Җилаяк ятып кала шунда. Кояш чыгып, тәнен кыздыра башлагач уянса, карчык юк. Җилаяк, ике итәген төреп алып, тегенең йөгереп киткән эзен күреп китте артыннан. Төш җитәр вакытта карчыкның артыннан барып җитте. Учын тутырып бер уч ком алды.

— Куып җиттеңмени, балам? — дип, әйләнеп караган иде карчык, Җилаяк:

— Җиттем! — дип, учындагы комны тегенең күзенә сипте.

Карчык, күзен уып, егылып калды шунда. Җилаяк мәйданга барып утырды. Кич булды дигәндә карчык та килеп җитте.

Патшаның эше барып чыкмады бит инде.

— Инде ниең калды, күңелең булдымы? — ди Дутан батыр.

— Атларны да, көрәшчене дә, йөгерешчене дә сынадык,— ди, патша әйтә.— Инде укчыларны сынап карыйк,— ди.

Патша кырык аршинлы бер багана утырттыра, элеп куя бер янчык алтын:

— Менә шуны кемнең угы йолып китә, алтын шуныкы,— ди.

Укчылар килеп ук ата башлыйлар. Янчыкка кайсыныкы эләкми, кайсыныкы яннан китә. Арып беттеләр ата-ата. Дутан җибәрә хәзер теге үрдәк атучыны. Әйтә тегеләрнең аучыларына:

— Чамагыз килмәде, ахры, менә мин атканны карап торыгыз,— ди.

Аягын нык басып, төзәп торып атып җибәрә. Моның угы, янчыкны йолып алып, күктә гаип була. Барлык кеше югары күзне сала — күренми. Бу әйтә:

— Бүген көтмәгез, иртәгә төш вакытына төшә торган ул, ди, юкка муеныгызны талдырмагыз, кайтыгыз,— ди.

Тәүлек тулганда янчык багана төбенә килеп төшә.

Дутан батыр тагы да әйтә:

— Тагы да күрсәтер үнәрең бармы әле? — ди.

Патша әйтә:

— Бүген кич булды. Иртәгә башланыр. Кызым синеке,— ди.

Өенә кайткач, теге вәзир әйтә патшага:

— Әгәр бирсәк, бу акылга сыймый торган эш, ди. Бүген төнлә бер хәйлә корырга кирәк безгә, ди. Яхшы атлар, яхшы тарантаслар җигеп, яхшы егетләр сайлап, ди. Көнекәйне йоклаган җиреннән сандыкка салып алып китсеннәр бер якка,— ди.

Вәзир кушканча, атлар әзерләп, кызның йоклаган җиренә барып, сандыкка салып алып киттеләр. Безнең әле теге җир тыңлап яткан бабай бар иде бит, боларның эшләгән эшләрен шул сизеп, Дутанга әйтә:

— Кызны сандык белән арбага салып алып киттеләр,— ди.

Дутан батыр, ачу белән торып, атына менде, коралланды, иптәшләренә кычкырды:

— Коралланыгыз, вәйран итәм, тере җан калдырмыйммын.

Кошлар белән уйнап йөргән бер бабай бар иде бит әле, шул әйтә Дутанга:

— Юкка кан түкмик, җан кыймыйк, ди. Мин аны, югары ук күтәрелеп очып китмәсәләр артларыннан барып, күзләрен бәйләп, сандыкны күтәреп алып кайтам, ди. Атларын арбага салырмын да, арбаларын үзләре тартып китерерләр, ди. Бер гаҗәп эш эшлим әле,— ди.

Һәм шулай барып сандык белән кызны алып килде Дутан янына. Ат җигеп китүчеләр күзләрен ачып карасалар, атларын арбага салганнар, үзләре арбаны тартып кайталар. Болар акылларыннан шашып калдылар хәзер.

Әйдә алар шашып торсын әле.

Дутан батыр Тел-Коңгыз дигән атына сандыкны нытытып бәйләп, алтавысы да кайтыр якка әйләнде хәзер. Төннәр узып, таң атканнан соң, бер җиргә туктап, сандыкның йозагын теш белән суырып ачса, ялтырап Көнекәй килеп чыга. Боларга бик зур шатлык туды. Барысы бердәй сөенәләр хәзер. «Үземнең ярыма кавыштым»,— дип, кыз да бик сөенә. Кайта-кайта торгач, Җалмавызга якынлаштылар. Дутан шунда башлап әйтә инде:

— Көнекәй, син минем үзем өчен түгел идең бит, ди, мине Җалмавыз карчык җибәргән иде, сиңа шунда калырга туры килә инде,— ди.

Көнекәй әйтә:

— Мин теләгемә юлыктым, дип әйтеп сөенеп торганда, син мине ничек анда калдырасың? — ди, канлы яшь белән җылый башлый.

Кызның сөйләп-сөйләп, канлы яшь белән җылаганын күргәч, чыдый алмый бар да җылаштылар шунда.

— Һәркайсыгызның кешегә көче җитәрлек кешеләр сез, ди, шул карчыкны да җиңә алмыйсызмыни? Ничек кыеп калдырып китәрсез мине? — ди кыз.

Дутан батыр шунда гайрәтләнде:

— Син үлгән җирдә мин дә үләм, сине ялгыз калдырмыйм,— ди.

Җир тыңлаучы бабай әйтә:

— Бу турыда юкка шашынырга ярамый, бер акыл кирәк хәзер, акылсыз була торган



эш түгел бу, ди. Менә Җилаяк кызлар шикелле, бик матур икән, яшь икән үзе, ди. Ял урынына ял тагын үсәр, бер атның ялын кисеп, Җилаякка чәч куйыйк та, шуны алып барып бирерсең,— ди.

Шулай итеп, Җилаякны Көнекәй итеп киендереп, бер атка Дутан батыр белән икесе менеп, Җалмавызга карап киттеләр. Тел-Коңгызга Көнекәйне атландырып, иптәшләре кайтыр юлга чыктылар. Дутан батыр барып-барып, Җалмавызның торган җиренә якынлаша. Җалмавыз моны сизеп каршы чыга.

— Алып кайттыңмыни, каһарманым? — ди.— Иң батыр кеше син икәнсең,— ди.

Өенә алып керә. Пылау пешерә. Дутан батыр аннан-моннан капкалый да әйтә:

— Минем әти-әни сагына торгандыр, мин, әби, кайтам инде,— ди.

Җалмавыз белән исәнләшеп, чыгып китә. Җилаяк шунда кала. Җилаяк: «Ух!» — дигән була, көрсенгән була.

— Әби, минем тышка чыгасым киләдерие,— ди.

— Тышка чыгып йөрмә, балам,— ди, Җалмавыз карчык әйтә,— менә бәләкәй ләгәнгә генә утыр шунда,— ди.

Җилаяк әйтә:

— Минем алай өйдә иткәнем юк шул, тышка чыгамын мин,— ди.

— Алайса мин дә синең белән чыгам,— дип, бергә тышка чыктылар.

Җилаяк тора да әйдә йөгерергә. Җалмавыз сикереп тора да менә куа башлый хәзер... Киң балаклы ыштан кигән икән бу карчык, йөгерә торгач бер-ике җирдә чалынып егылды. Ыштан балаклары өзелеп беткәч бик нык куарга тотынды бу Җилаякны. Җилаяк иптәшләренә килеп кушылды. Җалмавыз да бик якын калды инде. Барын бергә йотмакчы булып килә бу. Болар бик куркыштылар. Шуннан кош атучы кеше, җәясен төзәп торып, Җалмавызның маңгаендагы күзенә атып җибәрде. Теге килеп җитим дигәндә, ук моның күзеннән үтеп, миләрен актарып чыгып китте. Җалмавыз шунда ямьсез тавыш белән кычкырып егылды. Үлде бу шунда. Үлгәннән соң, Дутан әйтә инде иптәшләренә:

— Минем, шушы йөзе караның йомышында йөреп, ничә ел гомерем зая үтте. Моның малы безгә хәләл,— ди.

Җалмавызның өенен актарып, бик күп алтын-көмешләр алдылар.

Инде өйләренә якынлаштылар, бик аз калды. Көнекәйне үз атына атландырды да, Тел-Коңгызга Дию-чалны атландырып, атасына сөенче алырга җибәрде.

Моның ата-анасы: «Кайтырмы, юкмы балабыз?» — дип, зар җылап утыралар икән. Анасы бигрәк тә җылый икән: «Башкаларның баласы бар да тәгәл, минем ялгыз балам кайтмый лабаса»,— ди икән. Шулай итеп торган чакта Дию-чал кайтып керә. Дутанның атасының башындагы бүреген алып кия:

— Сөенчең бармы, улың кайта,— ди.

Шуннан һәркайсы йөгерешеп каршы чыгалар. Кочаклашып күрешәләр, җылашалар шатлыктан. Аталары бер шәп өйгә Дутан белән Көнекәйне кертә. Шуннан соң моның биш иптәшенә биш кызын бирә. Бераз рәхәттә гомер кичергәннән соң, атасы әйтә Дутан батырга:

— Җалмавыздан котылдың, Көнекәй белән кушылдың, ди, инде агаңнарны да, ил табып, өйләндер, ди. Алар да мин исән вакытта парлы булсыннар иде,— ди.

— Агайларга түгел, апаларга да кияү табармын, иярегез миңа,— дип, Дутан батыр алып чыгып китә боларны. Ил табып, тиз генә өйләндереп кайтмакчы була инде бу. Бер шәһәргә килеп җитәләр. Шәһәргә керергә кич була. Шәһәр читендә атларны тышау-

лап җибәреп куналар. Болар йоклап ята. Йоклап ятканда бик ачы ямьсез тавыш ишетелә. Дутан батыр агаларына әйтә:

— Бу нинди тавыш? — ди.— Барып белеп килегез,— ди.

Бер-икесен җибәрә. Барсалар, ул шәһәрне яу камап алган, таларга килгән икән. Халыкның шуннан куркышып җылаулары икән. Яу, шәһәр халкының барлык малларын әйдәп, матур-матур хатын-кызларын алып китә икән. Шәһәрдән куа чыгалар. Куа чыксалар да, кире кайталар. Җиңелдек без, диләр. Моның абзалары бик ачуланышып кайталар.

— Эзләп тапкан илебезне яу чабып китте,— диләр.

Дутан батыр әйтә:

— Аның өчен нигә кайгырасыз? — ди.

Иртәгесен Дутан батыр абзаларына әйтә:

— Атыгызга менегез, әйдәгез минем белән,— ди.

Һәркайсы атка менә. Дутан батыр башлап алып керә шәһәргә. Тегендә дә халык, монда да халык җыелышып тора. Патшалары да шунда.

Дутан батыр әйтә:

— Нинди дошманыгыз бар иде? — ди.

Патшалары әйтә:

— Күптәннән бирле дошман күреп килгән бер кешем бар иде, шул талап китте,— ди.

Дутан батыр әйтә:

— Ул яу беркая да бара алмас, бир миңа биш йөз кеше, артыннан куа чыгам, ди. Ул кешеләр сугышыр өчен түгел, малларыгызны танып алыр өчен кирәк,— ди.

Патша хәзер кешеләр хәзерләп бирә. Дутан батыр башлап алып китә, агалары да бара шунда бергә. Куып киттеләр. Өч көн эчендә яуның артыннан барып җиттеләр. Дутан батыр гаскәрнең арасына ач арыслан шикелле барып керде. Кайсын кылыч белән чаптыра, кайсын аты белән таптата; теге читтән керә, бу читтән килеп чыга; дошман явы Дутанның каһәреннән, кычкырган тавышыннан куркып кача башлады. Кайсы тал арасына кача, кайсы кая кача. Дутан батыр гаскәрне кырып бетерде. Үзенә ияреп барган кешеләргә малларын җыярга кушты:

— Алыгыз хатын-кызларыгызны, алыгыз малларыгызны,— ди.

Кайтыр юлга юнәлделәр хәзер. Думбралар чиертеп, кубызлар тартып, курайлар уйнап шатлык белән кайтып керделәр. Шәһәр халкы үзләренең малларын танып-танып алдылар, ди. Бу шәһәрнең патшасы Дутан батырны кочаклап алды, ди.

— Без дус булышыйк, мин сине үз урыныма патша итеп күтәрәмен,— ди.

Дутанның агаларына беренче кызларны бирә. Һәркайсы парлы була. Шунда туй итеп, тамаша итеп, бер кырык көннәр булды дигәндә, Дутан батыр өенә кайтмакчы була. Патшага әйтә шунда:

— Мин үз илемә кайтамын,— ди.

Патша әйтә Дутан батырга:

— Һәрвакыт яудан куркып, кан-яшь җылап торганчы, мин дә синнән калмыйм,— ди.

Дутан батыр әйтә шунда халыкка:

— Берегез дә калмый иярегез, ун мең сыя торган җәйләвем бар,— ди.

Шул шәһәрнең бар халкы Дутанга ияреп кайтып, һәркайсы йорт-җир корып, Дутан батыр бик гадел булып, шул тирәдәге барлык халыкны үз авызына каратты, ди. Бик яхшы гомер сөрделәр, ди.

эчтәлек

Камыр батыр 3



Турай батыр 9

Чура батыр 19

Таңбатыр 53

Дутан батыр 71

Литература для детей и юношества

Пять богатырей

Татарские народные сказки

Төзүче мөхәррире *Н.М.Вәлитова.* Бизәлеш мөхәррире *Л.К.Җәләлетдинова.*
Компьютерда битклә салучы *Н.П.Клипова.* Техник мөхәррире *А.С.Газизҗанова.* Корректоры *З.А.Даутова.*

Нәшрияткa 0201 нче номерлы лицензия 1997 елның 22 августында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 17.11.2000. Форматы 60×90 1/8. Офсет кәгазе № 1. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 10,5+форз. 0,5. Шартлы буяу-оттиск 45,0. Нәшер-хисап табагы 8,4+форз. 0,88.
Тиражы 5000 данә. Заказ А-120.

Татарстан китап нәшрияты. 420503. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420503. Казань, ул.Баумана, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/ E-mail: tki@books.kazan.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.